ТОРАК БӘЯСЕ

Казанда фатир бәяләре 140 процентка арткан

> 5

НИКАХ КИЛЕШҮЕ

Ир белән хатын байлыгы ничек бүленә?

> 16

ЛЮЦИЯ ХӘМИТОВА:

«Һәрбер рольнең үз авырлыгы бар»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 127 (28900) | Җомга | 2 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

Илдар Мөхәммәтҗанов

ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ!

УКУ ЕЛЫ ҮЗГӘРЕШЛӘРГӘ БАЙ БУЛАЧАК

Быел республикада 55 меңнән артык укучы тәүге тапкыр парта арасына утырды. Белем көнендә 9 яңа мәктәп ачылды. Укучылар линейкада дәүләт әләмнәрен күтәрде, гимн башкарды. Яңа уку елын ватанпәрвәрлек хисләре белән шулай башлап җибәрү бик әйбәт. Алда укучыларны «Мөһим сөйләшү» дигән яңа дәресләр дә көтә әле. Мәктәптә телефон куллануга да чикләүләр кертелде. Укытучылар өчен дә сөенечле хәбәр: кәгазьләрне икеләтә азрак тутыра башлаячаклар. Быелгы уку елы җитди дә, җиңелрәк тә булырга охшаган.

> 15

Ишетми калмагыз

Россиядә 1 сентябрьдән җиңел автомобильләргә техник тикшерү үткәрү буенча яңа кагыйдәләр эшли башлады. Хөкүмәт карары нигезендә хәзер таләпләр исемлегеннән мәҗбүри саналган 27 пункт чыгарыла.
Шулай итеп, техник белгечләргә 82 пункт урынына бары тик 55не генә контрольдә тотарга кирәк булачак. Хәзер техник карау транспорт чарасында аптечка, янгын сүндерү җайланмасының һәм авария тукталышын аңлаткан юл билгесе булуын күзәтүне күздә тотмый. Әмма юл хәрәкәте кагыйдәләре әлеге кирәк-яракларның машинада булуын элеккечә таләп итә.
Май һәм башка сыеклыклар тамып торуны, газ торбасыннан чыга торган тавыш дәрәҗәсен үлчәү, номерларны дөрес кую, машина урлауга каршы җайланма, тәрәзә юдыргычлар эшен, тормоз системасының коррозиягә каршы элементларын һәм тормоз торбаларындагы җитешсезлекләрне тикшерү дә мәҗбүри түгел.

Сентябрьдә октябрь суыклары көтелә. Бу хакта Казан федераль университеты профессоры Юрий Переведенцев хәбәр итә. Киләсе атнада һава температурасы климатик нормадан түбән булачак дип кисәтә белгеч.
«Хәзер көз, һава торышы да, температура фоны да тиз үзгәрә. Киләсе дүшәмбедән башлап температура 4–5 градуска түбәнрәк булачак. 5 сентябрьдән көндезге температура – 14, кичкесе 7 градус чамасы җылы торачак. Бу – сентябрьчә түгел, ә октябрь һава торышыдыр», – диде профессор.
Аның әйтүенчә, мондый һава торышы Россиягә арктик һава чыгуын тәэмин итүче салкын фронтның килүенә бәйле. Аның каравы җәйнең соңгы ае коры һәм эссе булып истә калды.
«Август үзенчәлекле ай булды. Ай буе бер тамчы яңгыр яумады. Уртача температура да климатик нормадан 5 градуска артып, 23 градусны тәшкил итте», – диде ул.

Республикада өченче көн инде коронавирус белән чирләүчеләрнең 300дән артык очрагы теркәлә. Республикада инфекция йоктырып авыручылар саны арта бара. Әйтик, соңгы тәүлектә аларның саны 366га җитте. «Стопкоронавирус.рф» порталы мәгълүматлары шул хакта сөйли. Сырхауларның 107се хастаханәгә озатылган. Шул арада 39 кеше сәламәтләнеп чыккан.

Татарстанда һавада төтен барлыкка килүне белгечләр күрше төбәкләрдәге урман янгыннарына бәйләп аңлата. Республиканың гидрометеорология үзәге мәгълүматларына караганда, һавадагы зарарлы матдәләр концентрациясе нормадан артмый.
Шулай да, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстандагы идарәсе халыкка урамда артык озак йөрмәскә киңәш итә. Белгечләр, мөмкинлек булса, өйдә утырырга, тәрәзәләрне ачмаска, ачык һавада физик эшләрне киметергә, уен мәйданчыкларында балаларны озаклап уйнатмаска тәкъдим итә. Баш әйләнү, тын кысылу, ютәл, йокысызлык, хәлсезлек сизсәгез, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

«СПАРТАК» ТҮГЕЛ – IT ПАРК

«Татар-информ» / Владимир Васильев

Ярты елда башкарылган зур эш. Республика тагын бер корылмага артты. Башкалада яңа IT парк кулланылышка тапшырылды. Бәйрәм көнендә һәм Цифрлаштыру елында сафка баскан иң зур бина бу. Яңа мәйдан Татарстандагы һәм илдәге IT тармак үсешенә этәргеч бирер дип өметләнәләр.

Татарстанда барлыгы өч IT парк бар. Казанда хәзер – икәү. Яңасы СССРда беренче электрон исәпләү машинасын («Стрела» һәм «Урал». – **Авт.**) уйлап табучыларның берсе Бәшир Рәмиев исемен йөртәчәк. 47 мең кв. м мәйдан мәгълүмати технологияләр юнәлеше буенча эшләүчеләр өчен 3–4 меңләп яңа эш урыны бирәчәк, 300ләп резидент урнашачак, барлык компанияләр елына 20 млрд сум күләмендә акча китерәчәк. Үзәк Казанның яңа тарту көченә әйләнер дип тә хыялланалар.

Паркны ачу тантанасында катнашкан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та шул өметтә. Ул әлеге проектның кыска вакыт эчендә – нибары алты айда тормышка ашырылганын искә төшерде.

– Иң матур урында бик матур бина сафка басты. Якында гына – «Школа 21», тагын бер IT парк. Бу урын үзенә җәлеп итеп торачак. Шушы мәйданда урнашып, эшләргә ниятләгән компанияләр барлыгын әйттеләр инде. Без бары тик шат кына, – диде Рөстәм Миңнеханов тантанада.

Сүз уңаеннан, республиканың мәгълүмати технологияләр тармагында 2700ләп компания һәм 40 мең кеше хезмәт куя. Бу гына аз әле, ди Президент та. Ә бит Татарстан өчен IT өлкә ят тармак түгел.

– Яңа паркта зурлар өчен дә, яшьләр өчен дә кызыклы булсын, дидек. Бар нәрсә дә балачактан башлана. Парк эчендә кечкенәләр өчен дә IT парк бар. Бу паркта киберарена да булачак. Яшьләр киберспорт белән кызыксына. 2024 елда исә, билгеле булганча, «Киләчәк уеннары»н кабул итәчәкбез. Моңа әзер булырга кирәк, – дип искәртте Президент.

> **Мәгълүмат өчен**
>
> IT парк нәрсәдән гыйбарәт? Беренче катка теләгән һәркем керә ала. Бирелә каһвәханә, чәчтараш, аптека, почта, банк бүлекчәләре урын алган. Сатучысы булмаган кибет тә эшли. Тамак ялгап алу өчен урыны да, типография дә бар. Балалар һәм яшьләр өчен кызык булырдай мәйданчыклар да – шушында.
> Икенче кат исә – тармак белгечләре өчен. Монда IT өлкә белән мавыгучыларга барысы да каралган: бизнес-инкубатор, китапханә, 600 кешегә исәпләнгән зал, киберполигон, офис. 3–7 катларда резидент булып урнашачак компанияләр өчен офислар бар.

Рөстәм Миңнеханов IT паркның ни өчен нәкъ тә Бәшир Рәмиев исемен йөртәчәген дә аңлатты.

– Бәшир Рәмиев – атаклы татар егете, 1948 елда беренче исәпләү машинасын уйлап табучылардан. Шул вакытта ук безнең сәләтле егетләребез булган! Цифрлаштыру тармагы тарихына керерлек лаеклы кеше табарга тырыштык, – диде ул.

Чарада Россия төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Ирек Фәйзуллин да катнашты. Мәскәү кунагы да Татарстанда сафка баскан корылмадан канәгать калуын яшерми. Проектның катлаулы булуын беләләр бит.

– Горурлык хисләре кичерәм. Элгәрәк мин дә шушындый зур объектлар ачуда катнаша идем. Бу яңа технопарк мин катнашмаган беренче IT парктыр. Шуңа да яхшырак килеп чыккан ул, – диде министр, уенын-чынын бергә кушып. – Ел җиңелләрдән түгел. Шулай да Россиянең төзелеш тармагы уңышларга ирешә. IT парк төзелеше катлаулы булды. Шундый кыска вакыт эчендә аны башкарып чыгу да – искиткеч очрак.

Тантанада Бәшир Рәмиевнең туганы – Бату Рәмиев тә чыгыш ясады.

– Бәшир Рәмиев – танылган шагыйрь Дәрдмәнднең оныгы, Рәмиевләр нәселе вәкиле. Алар барысы да бу җирдән. Рәмиевләр – татар мәдәнияте, сәнгать, технологияләр тармагы үсешенә салы өлеш кертүчеләр. Үз байлыгын алар халыкка да бүлеп биргән, мәчет-мәдрәсәләр, мәктәпләр, китапханәләр төзегән. Бәшир Рәмиев исә – беренче математик машинаны уйлап тапкан кеше. Моннан соң дөнья да үзгәрә! – дип чыгыш ясады ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Республика көне Татарстан халкы һәм кунаклары өчен Цифрлаштыру көне буларак та истә калмагае әле. Ник дигәндә, 30 августта Меңьеллык паркында «ТатарстанКиләчәк» цифрлы чынбарлык фестивале узды.
– Бик эчтәлекле, кызыклы фестиваль. Мондый чараларны алга таба да оештырачакбыз. Тормыш рәвеше үзгәрә бит. Цифрлы хезмәтләр безнең көнкүрешкә ныграк керә башлады. Республикада дәүләт хезмәтләрен үстерү, цифрлаштыру җәһәтеннән күп эш башкарыла. Бу эштә без яшьләргә таянабыз, – диде Рөстәм Миңнеханов әлеге чарада.
Фестивальдә цифрлаштыру, мәгълүмати технологияләр тармагына бәйле төрле бәйгеләр, лекцияләр, уеннар оештырылды. Чарада дистәләгән мең кеше катнашты.

ЯШЕЛ УРТАЛЫК

«Казан Экспо» күргәзмәләр үзәгендә Татарстан нефть-газ химиясе форумы уза. Аны ачу тантанасында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты. Форумда сәнәгать һәм икътисадны үстерү белән бергә табигатьне саклау турында да сөйләшәләр.

«Форум мәйданчыгы яңа эшлекле элемтәләр урнаштыру һәм хәзерге кризиска каршы көчне берләштерү өчен нәтиҗәле корал булыр дип ышанам», – диде Президент ачылу тантанасында. Бирелә Россиянең ягулык-энергетика комплексын декарбонизацияләү, импортны алыштыру һәм цифрлаштыру, Россия нефть-газ химиясе комплексы предприятиеләрен кадрлар һәм инженерлар белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча фикер алышалар. Эшлекле программада 2 меңнән артык кеше катнаша. Махсуслаштырылган күргәзмәдә Россиянең 25 төбәгеннән һәм 4 чит илдән 160тан артык алдынгы компания үзен күрсәтә. Форумда «Түбән Кама нефть химиясе» ГАҖ һәм «Алабуга» МИЗ арасында яңа төзелә торган «Этилен 600» индустриаль паркы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген алып бару турында килешү имзаланды. Әлеге проектка 1,3 трлн сум күләмендә инвестицияләр җәлеп итү күздә тотыла. Бирелә урнашачак резидентлар медицина, төзелеш һәм ТКХ тармаклары өчен продукция җитештерәчәк.

Форум кысасында узган фәнни-гамәли конференциядә экология иминлеге турында фикер алыштылар. «Сәнәгать иминлеге, «яшел» технологияләрне гамәлгә кертү мәсьәләләре һәрвакыт көн кадагында булачак. Россия Президенты Владимир Путинның парник газлары чыгаруны киметү турында Указы җәмгыятьнең чиста һава, эчәргә яраклы су, урман һәм басуларга булган табигый ихтыяҗына тулысынча туры килә», – диде Татарстан Президенты. Ул әлеге мәсьәләне хәл итү өчен дәүләт, бизнес һәм җәмгыять тырышлыгын берләштерү кирәклеген әйтте.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, бүгенге дөньяда барлык процесслар углеводородлар куллануга бәйле. Арзан энергия ресурслары – илкүләм икътисадның көндәшлеккә сәләтле булуының төп һәм кирәкле шарты. «Углеводородлар – ягулык һәм энергия генә түгел, ә нефть химиясе өчен иң кыйммәтле чимал да», – диде Президент. Ә нефть-газ химиясе комплексы – Татарстан икътисадының нигезе. Сәнәгать җитештерүендә аның күләме 63% тәшкил итә. Узган ел нәтиҗәләре буенча республика территориясендә 34,5 млн тонна нефть чыгарылган, 20 млн тоннадан артык «кара алтын» эшкәртелгән. Татарстанда эре сәнәгать проектларын гамәлгә ашыру дәвам итә.

«Татарстан, нефть чималы чыгару һәм эшкәртү өлкәсендәге компетенцияләр үзәге буларак, җитештерүдә экологик иминлеккә арттыруга һәм парник газлары чыгаруны киметүгә зур игътибар бирә», – диде Президент һәм моның өчен яңа технологияләр кулланыласын әйтте. Шул ук вакытта «яшел» технологияләргә күчкәндә, бизнес һәм җәмгыять мәнфәгатьләре исәпкә алынырга тиеш. Декарбонизацияләү эшендә исә чит илләрнең тәҗрибәсенә игътибар биреләчәк.

«Казан Экспо»да нефть химиясе продукциясен төзелештә куллану турында да фикер алыштылар. Бу мәсьәлә белән ныклап шөгыльләнү өчен, Татарстанда эшче төркем төзеләчәк.

Форум кысасында Татарстан Президенты Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең энергетика һәм инфраструктура министры Сухәйл Бин Мөхәммәд Әл Мазруи һәм Бәхрәйннең нефть һәм экология министры доктор Мөхәммәд Бин Мөбарәк Бин Даина белән очрашты. Очрашуларда ике арадагы хезмәттәшлекне үстерү турында сүз барды.

ЮГАЛТУ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Татнефть» генераль директоры Наил Мәгановка, абыйсы вафат булу сәбәпле, кайгы уртаклашу телеграммасы юллады.

«Хөрмәтле Наил Өлфәт улы! Абыегыз Равил Өлфәт улы Мәгановның кинәт вафат булуы турында хәбәрне ишетеп тетрәндем. Аның китүе – Сезнең өчен, бөтен гаиләгез өчен кире кайтара алмаслык югалту, Татарстан Республикасы, ил өчен авыр хәсрәт. Равил Өлфәт улы илебез нефть тармагының танылган профессионалы иде, аны алга җибәрү өчен гомере буе актив хезмәт итте, озак еллар дөнья күләмендә иң зур нефть компанияләренең берсе «ЛУКОЙЛ» ГАҖ топ-менеджментында эшләде. Абруйлы җитәкче, энергияле һәм максатка омтылучан кеше буларак, ул һәрвакыт туган республикасына тугры калды, тел-теш тидергесез вәкаләтлелек һәм эшкә бирелгәнлекнең, тормышка һичсүзсез уңай, иҗади мөнәсәбәтнең якты үрнәге булды. Равил Мәганов татарстанлыларның рәхмәтле хәтерендә дә шулай калыр. Сезнең белән бергә ихлас кайгырам, газиз кешегезне – Сезнең өчен иң якын дус, яхшы киңәшче, эштә дә, тормышта да өлгә булган абыегызны югалту хәсрәтен уртаклашам. Абыегыз турындагы якты истәлекләр, туганнарыгыз һәм якыннарыгызның теләктәшлеге Сезгә бу күтәрә алмаслык зур кайгыны кабул итәргә һәм үткәреп җибәрергә булышсын иде. Бирешмәгез, Сезгә көч һәм ныклык телим», – диелә телеграммада.

«ЛУКОЙЛ» компаниясенең вице-президенты Равил Мәгановның үлеме турында пәнҗешәмбе билгеле булды. Мәскәүдә вафат булган нефтьчегә 67 яшь иде.

БЕРЕНЧЕ КЫҢГЫРАУ

Яңа уку елында республика мәктәпләрендә 491 меңгә якын укучы белем алачак. Шуларның 55299ы – беренче сыйныф укучылары. Республикада 1414 мәктәп эшли. Соңгы 11 елда Татарстанда 79 яңа мәктәп һәм 284 балалар бакчасы төзелде. Шулардан 11 мәктәп һәм 5 бакча быел ачыла. Мәктәпләргә 1 меңнән артык яшь укытучы килде. Укучылар, аларның әти-әниләре һәм укытучыларның шатлыгын республика җитәкчеләре дә уртаклашты.

ТҮБӘН КАМАДА – ИКЕ МӘКТӘП

Түбән Камада «Адымнар» күптелле мәгариф комплексын ачу тантанасында Президент Рөстәм Миңнеханов белән Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты. Уку йортын узган елның көзендә төзи башладылар. Мәктәп 1224 укучыга исәпләнгән. «Адымнар-Түбән Кама» «Түбән Кама нефть химиясе», «Түбән Кама шин» һәм «ТАНЕКО» компанияләре белән хезмәттәшлек итәчәк. «Бездә «Адымнар» мәктәбе кебек яңа уку формасы булу бик куанычлы. Бу – иң заманча технологияләр һәм укыту алымнары. Әлеге проектның инициаторы – Минтимер Шәрип улы Шәймиев. Балалар һәм ата-аналар бик канәгать булырлар, дип ышанам. Бу мәктәпнең стандарты бик югары, дөнья дәрәҗәсенә туры килә. Укучыларга укуларында уңышлар телим», – диде Президент тантанада. Минтимер Шәймиев әйтүенчә, «Адымнар-Түбән Кама» – Татарстанда бишенче күптелле комплекс. «Түбән Кама Россия шәһәрләре арасында аерым урын алып тора. Биредә бөтен дөньяга танылган көчле нефть химиясе комплексы формалаштырылган. Бу – берничә буын түбәнкамалыларның тырыш хезмәте нәтиҗәсе. Мин сезне әлеге искиткеч күптелле комплексның ачылуы белән котлыйм», – диде Дәүләт Киңәшчесе.

Президент Рөстәм Миңнеханов Түбән Камада инженерлар лицее һәм балалар бакчасы ачылышында да катнашты. 38 нче лицейга 1385 укучы кабул ителгән һәм 48 сыйныф тупланган. Биредә Түбән Кама химия-технология институты һәм Әлмәттәге Югары нефть мәктәбе өчен абитуриентлар әзерләнәчәк. «Эврика» балалар бакчасы 320 урынга исәпләнгән.

«АДЫМНАР»НЫҢ АЛТЫНЧЫСЫ – ӘЛМӘТТӘ

«Адымнар» күптелле мәгариф комплексының алтынчысы Әлмәттә ачылды. Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев әлеге проектны тормышка ашыруда ярдәм иткәннәре өчен Президент Рөстәм Миңнехановка, район һәм «Татнефть» компаниясе җитәкчеләренә рәхмәт әйтте. «Әлеге искиткеч мәктәпләрнең якты киләчәге бар. Без булдырабыз! Яңа мәктәптә белемгә һәм татулыкка беренче адымнар ясыйбыз», – диде Митимер Шәймиев. Дәүләт Киңәшчесе уку әсбаплары алу өчен мәктәп директоры Илшат Яруллинга 100 мең сумлык сертификат тапшырды. Әлмәттәге «Адымнар» мәктәбе дә 1224 укучыга исәпләнгән.

ЧАЛЛЫДА – ИҢ ЗУРЫ

Чаллы тарихындагы иң зур мәктәп 1,5 мең укучыга исәпләнгән. Белем бирү үзәген ачу тантанасында Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин катнашты. Укучыларны, аларның әти-әниләрен һәм педагогларны әлеге сөенечле вакыйга белән котлаганда, республика парламенты башлыгы Татарстанда мәгариф тармагын яңарту өчен күп эш башкарылганын әйтте. Фәрит Мөхәммәтшин фикеренчә, бүгенге шартларда тәрбиягә дә аерым игътибар бирергә кирәк. «Балаларга үз шәһәреңне, республикаңны, илеңне ярату хисләрен сеңдерү мөһим. Бу мәсьәләдә мәктәп нәтиҗәле эшләр дип өметләнәм», – диде ул. Мәктәпне 2022 ел башында төзи башлаганнар һәм 9 ай дигәндә эшләп тә өлгерткәннәр. Яңа уку елында барлыгы 40 сыйныфка укучылар җыялар. Бу уку елында 8–11 сыйныфлар булмаячак.

БЕЛЕМ КӨНЕ ГЕНӘ ТҮГЕЛ

Түбән Камада ашыгыч ярдәм тизрәк күрсәтеләчәк. Тукай районының Круглое Поле бистәсендә яшәүче 120 гаилә газлы булды. Көзнең беренче көне республикада Белем бәйрәме белән генә түгел, әнә шундый мөһим вакыйгалар белән дә истә калды. Тантаналы чараларда Президент Рөстәм Миңнеханов катнашты.

Ярдәм тизрәк киләчәк

Түбән Кама Үзәк район хастаханәсендә яңа ашыгыч ярдәм үзәге ачылды. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов фикеренчә, әлеге үзәк шәһәр халкына күрсәтелгән медицина хезмәтенең сыйфатын яхшыртырга ярдәм итәчәк. «Түбән Кама үсә, эш өчен дә, яшәү өчен дә уңайлы шәһәргә әверелеп бара. Нефть химиясе башкаласы, илебезнең эре сәнәгать үзәге бу. Әлеге үзәк шәһәр халкына күрсәтелгән махсуслашкан медицина хезмәтенең сыйфатын яхшыртырга ярдәм итәчәк», – дип белдерде Президент ачылыш тантанасында.

Алты катлы бинада барлык ашыгыч хезмәтләр урын алган. Биредә шокка каршы зал, операция бүлмәсе, реанимация палатасы, диагностика хезмәтен үз эченә алган бердәм кабул итү-диагностика бүлеге бар. Алар зур техноген бәла-каза, аварияләр булган очракта кешегә тиз арада ярдәм итәргә мөмкинлек бирә.

Рөстәм Миңнеханов «Түбән Кама термалары» сәламәтлек һәм ял итү үзәгендә дә булды. Бүген биредә термаль бассейннар, 14 төрле сауна һәм мунча, хамам, мини-аквапарк эшли. Монда дәвалау һәм профилактика процедуралары да узарга мөмкин.

Газлы булдылар

Кичә Тукай районының Круглое Поле бистәсендә яшәүче 120 гаиләнең йорты газга тоташтырылды. Аларның шатлыгын Рөстәм Миңнеханов та уртаклашты. «Әлеге йортларда яшәүчеләрне котлыйсым килә. 120 хуҗалык бүген газга тоташа. Бу – зур программа. Президент Владимир Путин «Газпром» алдына бурыч куйды һәм, әлбәттә, без бу программаны гамәлгә ашырган өчен рәхмәтле», – диде Президент.

Билгеле булганча, хәзерге вакытта илдә Россия Президенты Владимир Путин кушуы буенча социаль газлаштыру программасы гамәлгә ашырыла. Газлаштыруның беренче этабын – 2023 елга кадәр, икенчесен 2030 елга кадәр тәмамларга җыеналар. Әлеге программа кысасында Татарстанда газлаштыру өчен 13 меңнән артык гариза алынган. Газ куллана торган җиһазларны газ бүлү челтәрләренә тоташтыру өчен 11 меңнән артык килешү төзелгән.

Рөстәм Миңнеханов әлеге мөһим социаль проектны гамәлгә ашыруда катнашкан һәркемгә рәхмәт белдерде. «Ул безнең территорияләрнең җәлеп итүчәнлеген арттыра. 11 мең яңа хуҗалык ул – җитди ресурс. Чынлыкта без мөмкинлекләр югарырак дип саныйбыз. Алга таба да бу программаны дәвам иттерәчәкбез», – диде Президент.

«Газпром трансгаз Казан» оешмасының генераль директоры Рөстәм Усманов сүзләренә караганда, бүген республикада газлаштыру күрсәткече 99,5 процентка җиткән. Ул Россиядәге иң югары күрсәткечләрнең берсе санала.

Автокала шатлыгы

Рөстәм Миңнехановның эш сәфәре Чаллыда дәвам итте. Президент биредә капиталь төзекләндерүдән соң ачылган «Родник» халыклар дуслыгы йортын карады. Ул 2000 елдан бирле эшли. Монда 22 милли җәмгыять һәм 11 якшәмбе мәктәбе урнашкан. Рөстәм Миңнеханов 210 урынлы тамаша залын, хореография, милли-мәдәни берләшмәләрнең бүлмәләрен карап чыкты. Халыклар дуслыгы йортында төзекләндерү эшләре узган елның көзендә башланган. Бинаның түбәсе төзекләндерелгән, фасады ябылган, тәрәзәләр, ишекләр һәм инженерлык системалары алмаштырылган, эчке өлеше бизәлгән.

Рөстәм Миңнеханов Чаллыда «Мастеровые» рус драма театрының тантаналы ачылышында да катнашты. Әлеге бина 2020 елның октябрендә төзелә башлаган. Ике ел эчендә 13 мең квадрат метр мәйданлы 4 катлы зур бина сафка баскан. Театрның тамаша залы 500 кешене сыйдыра. Артистлар өчен исә 100 кешегә исәпләнгән репетицияләр залы да эшләячәк.

– Шәһәр халкының күптәнге хыялы чынга ашты. Илнең бөтен театр җәмәгатьчелеге өчен зур вакыйга бу, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Алабугада исә Президент катнашында Мәдәни үсеш үзәге һәм футбол манежы ачылды.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

«Әйдүк Хәмит»

Кешегә кушамат тагу – халык иҗатының иң югары дәрәҗәгә җитүе, дип санар идем. Ул – образлы фикерләүнең матур бер чагылышы. Фәлән кешегә генә хас сыйфатны күреп алу сәләте бөтенебезгә дә бирелми.

Безнең авылда кушаматсыз нәсел юк иде бугай. Хәер, без бар икән. Әтигә укытучы булган өчен кушамат такмаганнардыр, дияр идең, бездә кушаматсыз укытучы юк иде.

Каян табып бетерәләр, каян мач килеп тора диген! Хәмит абыйга кушамат ябыштыру өчен бер сүз җиткән. Ул өенә килгән бер кешене: «Әйдүк, әйдүк», – дип каршы ала торган булган. Күрәсең, «әйдүк» дигән сүз безнең авылда киң кулланылмаган, йә шулай дип әйтү бөтенләй булмагандыр. Юкса «әйдүк» сүзе Хәмит абыйга матур гына ябышып, аның нәселен гомер буе озатып бармас иде. «Әйдүк Хәмит малае», «Әйдүк Хәмит оныгы» дигән сүзләрне бүген дә ишетеп була. Иң кызыгы: аның нәселендә барысы да бик кунакчыл, ачык күңелле.

Кайда ничектер, безнең авыл кушаматлары бөтен Татарстанга таралган булган. Монысын безгә, әле башлангычта укыганда ук, Кузнәк Хафизы сөйләгән иде. Авылларга радио керә башлаган гына еллар бу. Халык арасында чыш-пыш тарала. Диндар картлар бигрәк тә тырышлык күрсәтә: имеш, радио тыңлау гөнаһ, кара тәлинкә эченә шайтан кереп оялаган. Радио тыңлаган кеше бозык юлга кереп китә...

Шуннан авылның алдынгы карашлы кешеләре үз араларыннан сүзгә бик оста саналган Сандугач Салихын Казанга, радиокомитетка юллыйлар. Икенче көнне авылдагы бердәнбер телефонга Казаннан шалтыраталар һәм фәлән сәгатьтә булачак тапшыруда безнең авыл кешесенең дә катнашачагын әйтәләр. Кара тәлинкәгә охшаган радио булган өйләргә халык җыела. Өйгә сыймаганнар ачык ишектән баскыч төбендә тыңлый.

Менә тапшыру башланып китә. Алып баручы көн яңалыклары белән кыскача гына таныштыра да тапшыру кунагына сүз бирә. Ә ул, исәнлек-саулык та әйтеп тормыйча: «Әй, Пытымыр Мәхмүзә, Капчыклы Шәмси, Күрәч Таһир, сез мине ишетәсезме? Радио эченә шайтан кереп оялаган дип, котку таратып йөрисез. Мине танийсызмы? Сандугач Салихы булыр бу!» – дип сүз башлаган ди. Мондый вакыйга булгандырмы, юктырмы – аның раславы кыен. Әмма ул яңа төсмерләргә байый-байый хәзерге көнгә хәтле килеп җитте. Монысы да – халык иҗаты. Безнең якта хәтта һәр авылның да үз кушаматы бар. Аларның килеп чыгуы да булган, яңа, булырга мөмкин вакыйгаларга бәйле. Ә ул вакыйгалар – халык авыз иҗаты энҗеләре сыман, бүген дә әледән-әле ялтырап китәләр. Кеше аларны арттырып, күпертеп, үзеннән әлләниләр өстәп сөйли һәм шуннан ләззәт ала. Без ярыша-ярыша ялганларга да күп сорамыйбыз. Ә белеп, кешене ышандырып ялганлау өчен үзенә күрә бер осталык, үзенә күрә бер талант кирәк. Ә ул бездә бар. Мин Арча якларын күз алдында тотам инде. Бу җирдә, ундырышсыз туфракта бу кадәр язучы, гомумән, иҗат кешесе чыга алмый, дип әйтәсе килә. Әгәр бүген исән булса, авылдашым, гомер буе тимерчелектә эшләгән Кәя Хөрмәте дә, җилкәмнән кагып: «Энем, дөрес сөйлисең», – дияр иде.

ЭПОХА БЕЛӘН БӘХИЛЛӘШҮ

Сишәмбедән чәршәмбегә каршы төндә мәгълүмат кырына СССРның беренче һәм соңгы Президенты Михаил Горбачевның үлеме турында хәбәр чыкты. Бу – атна вакыйгасы гына түгел, әлбәттә, тарихи бер чорның соңгы кайтавазы булып планетакүләм яңгыраган хәбәр.

Кайчандыр дөньяны шаулаткан лидерның җәсәде суынып та өлгермәде, Британиянең The Guardian газетасы үз сайтында дөнья масштабында танылган сәясәтчеләрнең Горбачев шәхесенә мөнәсәбәтен белдергән онлайн трансляция башлап җибәрде. Иң беренчеләрдән булып Кондолиза Райс һәм Арнольд Шварценеггерның тавышы ишетелде. Берлускони – Италиянең элекке Премьер-министры, хәзерге Россия лидерларының якын дусты – Михаил Сергеевичны XX гасыр тарихын үзгәрткән кеше дип атады. Арнольд Шварценеггер – Калифорниянең элекке губернаторы, әмма Терминаторны уйнаган актер буларак сиксәненче-туксанынчы еллар яшьләренең кумирына әверелгән шәхес: «Без барыбыз да аның фантастик тормышыннан сабак ала алабыз», – дигән сүзләр әйтте. БМО Генераль секретаре Антониу Гутерреш аның «салкын сугыш»ны тәгәлләү өчен бар кешедән дә күбрәк өлеш кертүче булуын билгеләп үтте, шулай ук тарихның хәрәкәтен үзгәртте дигән фикерне куәтләде.

Әйе, СССР лидерының вафаты белән зур эпоха соңгы кайтавазын бирде. Аның белән тыгыз аралашкан, дөньяның XX гасыр ахырындагы йөзен формалаштыруда зур өлеш керткән әйдәп баручы державаларның яисә идеологияләрнең лидерлары күпкә алдан киттеләр. Рейган, өлкән Буш, Тэтчер, Коль, Миттеран, Кастро, Кытай һәм Япония лидерлары, социалистик блок җитәкчеләре – барысы да әрвахлар инде. Махсус хәрби операция башланганнан соң, СССРны таркатуда төп рольләрне уйнаган өч лидер: Шушкевич (3 майда), Кравчук (10 майда), Горбачев (30 августта) мәңгелеккә күчтеләр. Бары тик Ельцин гына иртәрәк – 2007 елның 23 апрелендә вафат булды. 19 июньдә Ельцин командасының соңгы эшлеклеләреннән берсе Геннадий Бурбулис үлгән иде.

Кем ничектер, мин үзем бу үлемнәрдә символик мәгънә күрәм. 24 февраль элекке тормышның артта калуын, сикәлтәле һәм фаҗигале яңа эпоханың мәйданга чыгуын, кешелек тормышында яңа сызык сызылуын символлаштыра торган дата буларак тарихка язылды. Элекке лидерларның тәҗрибәсе дә, йогынтысы да яңа чор өчен кирәк түгел инде. Кызганычтыр һәм күзләрдән яшь китерерлек дәрәҗәдә аянычтыр: без тагын бер тапкыр тарих сәхнәсендә яңа зур драманың, бөек вакыйгаларның уйналуының шаһитларына әверелдек.

Горбачевны Көнбатышта киеренкелекне йомшартучы буларак байрак итеп күтәрәләр, үз Ватанында исә күпләр СССРны таркатучы хыянәтче итеп күз алдына китерә. Чынлап та, 1980 нче елларның уртасында киеренкелек шул дәрәҗәгә җитте: атом-төш ялкынында әнә-менә бөтен дөнья көяр төсле иде. Ашкынып коралланугa тотылган акча күтәрә алмаслыкка әйләнде. Яңа технологик кораллар бер-бер артлы мәйданга чыга һәм Көнбатыш, бигрәк тә аның лидеры булган АКШ СССРны уза башлады. Һәм стратегик, һәм тактик лидерлык алар кулында иде. Вашингтонда иң соңгы мизгелдә фантастик яңа технология – Стратегик оборона инициативасы (СОИ) белән Мәскәүне куркыта алдылар.



Галәм сугышларына юл ача торган бу инициатива тормышка ашырылса (чынлыкта ул тормышка ашырылрык булмаган инде, әлбәттә), СССРның барлык атом-төш ракеталары чүплеккә ташлана торган уенчыкларга әвереләчәк иде. Мәскәүдә КПСС лидерлары Горбачевка кадәр үк яхшы аңладылар: матди яктан да, интеллектуаль яктан да Көнбатышка җавап бирерлек җай калмаган иде инде. Җитмәсә, лидерларның бер-бер артлы үлеме (соңыннан «купшы җеназалар бишьеллыгы» дип аталачак чор) дәвамчанлык дигән нәрсәгә аяк чалды, илнең үсеш стратегиясе юк, киләчәктә ни эшләргә дигән сорауга җавап та табылмый иде.

Бертуктаусыз ялган пропаганда да ардырды. Массалар кибетләрдәге дефициттан, базарлардагы кыйммәтле муллыктан тәмам туйды. Көнбатыш пропагандасы миләргә үтеп керүнең җаен таба иде. Яшерен «тавыш»ларны төнлә тыңлау, алардагы фикерләрне «сарафан радиосы» һәм «самиздат» аша тарату модага әйләнде. Көнбатышның һәркемгә, бигрәк тә юксылларга ярдәм итә торган образы тудырылган һәм кешеләргә киресен ышандыру инде мөмкин түгел иде. Пропаганда белән тормыш чынлыгы шулкадәр каршылыкка керделәр: беренчесе укышыту реакциясе бирә башлады.

Горбачев менә шундый мизгелдә дилбегәне кулга алды. Көтмәгәндә ирек биреп, демократия, хәбәрдарлык дигән лозунгларны байрак итеп күтәреп, ул моңарчы булмаган популярлык яулады. Әмма үзе күтәргән байракның сабы аның үзен дә кыйный иде. Үзгәрешләр кирәк, әмма аларны ничек тормышка ашырырга икәнен беркем дә белмәде. Ул арада Ельцин шахмат тактасына килеп чыкты. Үзәк Комитетның төзелеш эшләре белән генә шөгыльләнүче секретаре – югары хакимиятнең түбәнге баскычларындагы шәхес бөек ат йөреше ясады, Горбачевны тәнкыйтьләп, популярлык яулады. Бераз гына соңрак патшалык таҗына да дәгъва итә башлады. СССР тарихында беренче тапкыр бөекләрнең сәхнә арты көрәше авансценага чыкты.

Шушы урында бераз гына туктыйк та искәртеп алыйк әле: бер генә шәхес тә тарихны үзгәртә алмый, алар бары тик тәкъдирдә язылган юлдан гына атлыйлар. Лидерларның идарәсе һәрвакытта да массаларның теләк-омтылышына туры килә. Халыклар ирекккә сусаган идеме? Сусаган иде. Бер туганның диктатыннан башка туганнар гарык булган идеме? Булган иде. Барыбыз да муллыкка кызыга идекме? Кызыга идек. «Көнбатыш безгә булышыр» дигән наив идея барыбызның да йөрәкләренә кереп урнашкан идеме? Түрдә үк иде. Горбачев һәм Ельцин харизматиклары менә шул идеалларны тормышка ашырырга керештеләр дә инде. «Халык нинди, идарәчесе шундый» дигән кагыйдә котылгысыз рәвештә тормышка ашырылды һәм ул һаман да эзлекле рәвештә тормышка ашырылып килә.

Горбачевны СССР таркалганда көч кулланмауда гаеплиләр. Союздаш республикалардагы бунтны бастыру өчен хәрби көчләр бер генә тапкыр хәрәкәткә китерелмәде ул елларда. Барысы да кире нәтиҗәгә генә китерделәр. Буа ерылса, ташкын каршында кем тора ала? Халыкларның ирекккә омтылышы «бәйләнчек идея» дәрәҗәсенә ирешә ул елларда. Менә карагыз: 1989 елның 23 августында, моннан нәкъ утыз өч ел элек, Балтыйк буенда Литва, Латвия һәм Эстониянең бәйсезлеген таләп итеп, 2 миллион кеше 600 километр арада кулга-кул тотынышып тере чылбыр хасил иттеләр. Урманнар, кырлар аша иңгә-иң терәлгән халык аягүрә басты. Өч республиканың гомуми халык саны 7,93 миллион иде ул чакта. Һәр дүртенче кеше «чылбыр»га тезелгән. Интернет юк, социаль челтәрләр юк... Горбачев нишли ала бу вазгыятьтә?! Ул еллар Казанын хәтерләгез. Ирек мәйданы ничек кайный иде? Халыклар диңгезе дулкынланган һәм шаулаган саен, Михаил Сергеевич кулыннан дилбегә шуа, аның җете популярлыгы тәссезләнә, «корольнең ялангач» икәнлеген бар кеше дә күрә башлый иде. Чынлыкта бернинди бөеклек юк, лидерларга ул эпитет һәрвакытта да ялгыш бирелә. Вазгыятьтән оста файдаланучы бүтән берәүнең югары калкуын вакыйгалар котылгысыз рәвештә таләп итә иде. «Суверенитетны күпме йота алсагыз, шуның кадәр алыгыз», – дип кем әйтте әле?

Соңгы чор вакыйгалары шуны күрсәтә: бу юлы бөтен кешелек дөньясы глобаль үзгәрешләрнең бусагасында тора һәм хәтта егылып төшеп үк килә. Бу лидерларның йомшаклыгында һәм көпшәклегендә дә күренә. Ни әйтергә икәнен кешедән сораган Байденны карагыз. Бертуктаусыз телефоннан Путинга шалтыратучы Макронга игътибар итегез. Дөрес булса, аңа каршы Мәскәүдә дә, Вашингтонда да зур компромат бар, шуңа өтәләнә, диләр. Шольц – Германиянең яңа лидеры, соңгы атналарда үз халкы тарафыннан сөңгеләр белән каршы алынучы шәхес, ниндидер хәлиткеч фикергә килә алмый интегә. Боларның барысын да түнтәрәчәк һәм көлке хәлгә куячак яңа лидерны вазгыять үзе таләп итә.

Бөеклек аурасы белән чолганып алынган Горбачев үлеме мине менә шулар хакында уйлата. Лидер үз теләге белән сәхнәдән вакытында китеп бармый икән, шиксез, үзенең көчсез бер адәм баласы гына икәнен раслап китә. 1997 елда оныгы белән Pizza Hut рекламасы роликында төшеп зур акча эшләгән Михаил Сергеевич гадәти бер актер гына иде, әмма тарихи вакыйгалар аны авансценага этеп чыгарды. Нишләтәсең, халыкның башын әйләндерү өчен шундый харизматик кирәк иде. Ул ролен башкарды, шуннан артыгына көчсез иде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

КЫЙММӘТЛЕ КУЫШ

КАЗАНДА ФАТИРЛЫ БУЛУ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Ел башыннан бирле Казанда яңа төзелүче йортлардагы фатирлар 30 процентка кыйммәтләнгән. Бу күрсәткеч буенча Татарстан башкаласы хәтта Россия төбәкләре арасында беренче урынга ук чыккан (таблицада. – Д.Г.). Сигез ай эчендә Казандагы яңа фатирларның бер квадрат метры 170 мең сумга (!) җиткән. Чагыштыру өчен: ел башында аның хакы 140 мең сумны тәшкил иткән. Алга таба ни булыр?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бер бүлмәле өстенрәк

Финанс аналитигы Александр Гусев фатирларның квадрат метр бәясе котырып үсүгә банклар тарафыннан 7 процентлы ташламалы кредит бирелә башлау сәбәпче дип саный. «Торак бәяләре, нигездә, 2020 елның икенче яртысыннан зур тизлектә үсә башлады. Ташламалы ипотека керттеләр, ә кулланылышка тапшырылган торак күләме җитәрлек дәрәҗәдә түгел иде. Шул рәвешле түбән ставка хисабына фатирларга сорау артты, әмма төзүчеләр сатуга торак җиткереп бетерә алмый тилмерде. Шул рәвешле фатирларның квадрат метр бәясе дә бик нык үсте», – ди белгеч.

Шул рәвешле күзгә таба фатир бәяләре бераз төшмәсме дип сабыр иткәннәрнең өметләре акланмады. Фатир бәяләре үскәннән-үсә генә бара. Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә май аенда Казанда 800 миллион сумга 687 фатир сатылганын хәбәр иткән идек. Июньнең беренче яртысында исә башкалада 200 миллион сумга 61 фатир гына сатылган иде. «Сравни Дом» агентлыгы мәгълүматларына караганда, май – июнь айларында бер фатир сата алмаган төзүчеләр дә булган.

Әмма июль аенда вазгыять үзгәрә башлаган. Татарстанда яңа йортлардагы фатирларга сорау – 30 процентка, искеләренә 23 процентка арткан. Халык элеккечә үк бер бүлмәле фатирларга өстенлек бирә. «Май аенда күзәтелгән түбән күрсәткечләрдән соң июль аенда торак базары кабат җанлана башлады. Җәй уртасында милек рәсмиләштерүчеләр саны, май ае белән чагыштырганда, 23 процентка артты. Аларның күбесе ипотека кредиты хисабына торaклы булла», – ди Татарстан буенча Росреестр идарәсе башлыгы Азат Җәббаров.

Татарстанның Риелторлар гильдиясе вице-президенты Руслан Садриев, Татарстанда милеккә сорау алга таба артачак, дип саный. «Торак базары елның-елында көзгә таба җанлана. Быел да искәрмә булмаячак. Ник дигәндә, җәйге чорда кеше фатир сату-алу мәшәкатен читкә куеп тора. Аннары сентябрьдә Казанга эшкә, укырга килүчеләр саны да арта. Бу исә фатирларга, аларны сатып алуга да, арендалауга да ихтыяҗны арттыра», – ди белгеч.

Аренда отышлырак

Соңгы елларда мөмкинлегә булган ата-ана студент баласына кечкенә генә гостинка яки бер бүлмәле фатир алып бирергә тырыша. Әмма белгечләр, быел мөнысы да сирәк күренеш булыр, дип фаразлый. Риелтор Дамир Сафиуллин бу очракта аякны юрганга карап сузарга киңәш итә. «Әгәр беренчел кертемгә җитәрлек акча бик аз булса, шуның аркасында ипотеканың айлык түләве 30 меңнән артса, студентны вакытлыча фатирга кертеп укытуың отышлырак, билгеле. Бер бүлмәле фатир өчен 30 мең сум кредит түләп яшәгәнче, шул ук бер бүлмәле фатирны 15 мең сумга арендалап торуың арзангарак чыга», – ди белгеч.

Бүген Казанда бер бүлмәле фатирны арендалап тору – 15 мең сум, ике бүлмәле фатир – 20 мең сум, өч бүлмәле фатир 22 мең сумга төшә.

Дамир Сафиуллин торак базарының бераз җанлана төшүен исә булган фатирын сатмыйча сабыр итүчеләрнең хәзер бу эшкә ныклап керешүе белән аңлата. Хәтерләсәгез, Үзәк банк төп ставканы ел башындагы күрсәткечкә кадәр төшергәч, җәй башында икенчел торак базарындагы фатирлар да очсызлана башлады. Саннар теләнә күчерсәк, алар уртача 5 процентка арзанайды. «Милекчеләргә, фатир сатканда, бәяләрне шактый төшерергә туры килде. Юкса фатир бик озак сатылачак бит. Шуңа күрә күпләр сатуга куйган фатирларын кире алды, бераз сабыр итәргә булды. Хәзер фатир сату турындагы бу игъланнар кабат күренә башлады», – ди риелтор.

Үз куышын булдырырга теләүчеләргә дә бу мәсьәләне хәзер кайгыртырга киңәш итә ул. «Торак бәяләренең очсызлануын көтәргә кирәкми. Моңа төзелеш материалларына бәя төшкән, төзүчеләрнең чыгымнары кимегән очракта гына ирешеп була. Әгәр кешенең кулында акчасы бар икән, фатирны хәзер алып кую яхшы. Күреп торабыз: вазгыять катлаулы. Мондый шартларда булган акчаны күчемсез милеккә тотудан да яхшысы юк. Акча үз кыйммәтен югалта гына бара», – ди ул.

Бүген алу хәерле

Казандагы билгеле милек агентлыгы җитәкчесе Анастасия Гыйззәтова фикеренчә, торак базары өчен быелгы июль әллә ни үзгә булмаган. Соңгы ун елдагы кебек быел да җәй уртасында торак базарында торгынлык күзәтелгән. Башкаладагы фатир бәяләренең котырып үсүенә исә ташламалы ипотека «гаепле» дигән фикердә ул да. «Әлеге программа халыкның үз куышын булдырырга мөмкинлекләре артсын дигән ният белән эшләнде. Әмма чынлыкта хәлләр башкачарак килеп чыкты. Ташламалы ипотекага сорау артты, шулай булгач, торак бәяләре дә арта, билгеле. Шул рәвешле яңа фатирларның гына түгел, искеләренең дә хакы бермә-бер артты», – ди белгеч.

Анастасия Гыйззәтова бүген Казанның Яңа Савин районында 33–34 квадрат метр мәйданлы бер бүлмәле «ленинградка» фатиры булганнарны иң бәхетле кешеләр дип атый. Ник дигәндә, мондый торак беркайчан да кыйммәтен югалтмый. «Андый бер бүлмәле фатирны теләсә кайсы вакытта сатарга мөмкин. Илдә кризис булу – мөһим түгел, аны бишкуллап алачаклар. Бер карасаң, искереп, тузып беткән ямьсез подъездлы мондый фатирлар беркемгә кирәк түгел кебек. Чынлыкта исә урнашкан районы һәм бәясенә күрә бу фатирларга сорау гел зур булып кала бирә», – ди агентлык җитәкчесе.

Бүген күп кенә оешмалар да элеккеге «хрущевка», «ленинградка» тибындагы кечкенә фатирлар төзеп сатуга өстенлек бирә башлаган. Халык бер квадрат метр өчен 200 мең сум чамасы артык акча чыгарып, 50 квадрат метрлы бер бүлмәле фатир сатып алырга атлыгып тормый, ди белгечләр. 34–36 квадрат метрлы кечерәк фатирларга өстенлек бирәләр.

Анастасия Гыйззәтова фикеренчә, соңгы айда торак базары бераз җанланса да, үз куышыңны булдыру әле дә күпләрнең хыялы гына булып кала бирә. Бүген кредит рәсмиләштереп торaклы булу да күпләрнең көченнән килми. «Халык әле дә торак бәяләренең түбәнәюен, ипотека ставкаларының төшүен көтә. Күреп торабыз: соңгы арада халыкның матди хәле сизелерлек начарланды. Күпләр яңа кредит рәсмиләштерү түгел, булганын да авырдан түли. Аннары апрель аенда Казанда фатир арендалауга сорау да бик нык кимеде. Шул рәвешле фатирын арендага биреп, шуннан кергән акчага кредитын ябып яшәүчеләрнең чыгымнары тагын да артты», – ди белгеч.

Бүген фатир алыргамы, сатаргамы, әллә бераз сабыр итәргәме, дип баш ватучыларга милек агентлыгы җитәкчесе тимерне кызуында сугарга киңәш итә. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ булган кешеләргә бу эшне хәзер эшләргә кирәк дигән фикердә ул.

– Фатирларның квадрат метр бәясе үсә бара. Шуңа күрә киләчәктә тамырдан уңай үзгәрешләр булыр дип көтеп утырудан мәгънә юк. Ана капиталы акчасы булган кешеләргә бигрәк тә. Билгеле булганча, өч яки аннан да күбрәк балалы гаиләләргә дәүләт хәзер ипотеканы каплау өчен 450 мең сум акча бирә. Ана капиталына шушы акчаны да кушсаң, сезнең кулда инде беренчел кертем өчен 1 миллион сум акча бар дигән сүз. Хәзерге шартларда бу акча көннән-көн очсызлана. Шуңа күрә аны милек алганда куланудан да яхшырагы юк, – ди Анастасия Гыйззәтова. – Бер фатирын сатып, зуррагын алырга теләүчеләргә дә бу эшне хәзер эшләү хәерле. Ә инде фатирны сату өчен алырга теләүчеләр әллә ни отмаячак. Бүгенге вазгыятьтә фатир сатудан элеккеге кебек икеләтә-өчләтә табыш алу мөмкин түгел.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЕЛ БАШЫННАН БИРЛЕ ЯҢА ТӨЗЕЛГӘН ЙОРТЛАРДАГЫ ФАТИРЛАРДА 1 КВАДРАТ МЕТР БӘЯСЕ КҮПМЕГӘ АРТКАН?

(«ЦИАН.Аналитика» мәгълүматлары буенча)

Шәһәр	2022 елның гыйнварында 1 кв. м бәясе (уртача)	2022 елның августында 1 кв. м бәясе (уртача)	Ел башыннан бирле үсеш
Казан	140,4	179	+27%
Ростов-Дон	93,8	118	+26%
Самара	78,1	97,5	+25%
Чиләбе	69,1	83,3	+21%
Воронеж	80,8	95,4	+18%
Санкт-Петербург	205,8	240,1	+17%
Түбән Новгород	118,9	137,7	+16%
Уфа	95,5	108,8	+14%
Красноярск	94,9	107,5	+13%
Волгоград	77,8	87,8	+13%
Пермь	92,6	104,3	+13%
Новосибирск	113,5	124,4	+10%
Екатеринбург	112,5	122,4	+9%
Омск	94,2	100	+6%
Мәскәү	305,5	321,2	+5%
Краснодар	125,9	129,6	+3%

Күпләр, көннәр коры, матур торганда, бәрәңгеләрен алып урнаштырып, бакчаларын чистартып та куйды. Быел уңыш нинди? Аны ничек дөрес сакларга һәм үзеңнән артканны нишләтергә? Шушы уңайдан без халык һәм фермерлар фикерен белештек.

vk.com

ИКЕНЧЕ ИКМӘК

Елына күрә яхшы

Мондый эсседә бәрәңге алган юк иде әле. Узган атнада аны казып, эшләрен бетереп куючылар әнә шулай ди. Чыннан да, 30–34 градус эсседә бәрәңге алган булмагандыр шул. Ләкин кемдер балаларының укулары башланганчы эшен бетереп куярга ашыкса, кемдер өлгергән булгач, уңышны һаман да җир астында яткыруны кирәксенмәде. Дөрес, араларында «күршедән калмыйк» дип тырышучылар да юк түгел. Ләкин, әле иртәрәк дип, сентябрьне, көннәрнең бераз суытып җибәргәнен көтүчеләр дә күп.

Беренчеләр арасында Чүпрәле районы Кече Чынлы авылы халкы да бар. Биредә ел да эшләрен башкаларга караганда иртәрәк тәмамлыйлар.

– Без, гадәттә, бәрәңгене май башында утыртабыз. Быел да 4 майда бер кат эшебез беткән иде инде. 26 августта алып, эшне бетереп тә куйдык, – ди Лилия Йосыпова. – Узган ел тагын да иртәрәк алган идек әле. Бәрәңге уңышы уртача булды, ләкин кышка җитәрлек. Эресе дә, вагы да бар. Бик вакларын кош-кортларга бирәбез. Безнең якларда яңгыр июль уртасында яуган иде. Шуннан бирле бер тамчы да төшмәде. Әни, августта яңгыр булса, уңыш мул буласы булган, ди. Быел бакча эшләре җирнең бик каты булуы белән аерылып тора. Узган ел бик рәхәт эшләгән идек, быел бик авыр булды. Әле ярый бакчабыз кечкенә. Елдан-ел киметә барабыз. Бакчаның биштән бер өлешенә генә бәрәңге утыртабыз. Калганында – печән һәм кабак.

Питрәч районының Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Николай Морозов сүзләренә караганда, быел авылдашлары бәрәңгене күпләп утырткан һәм бу көннәрдә барысы да казып алып урнаштыру белән мәшгуль.

– Яңгырлар аз булуга карамастан, уңыш әйбәт быел. Үзебезгә дә, балаларга да җитә, – ди Николай Морозов. – Безнең авылда бәрәңге сатып алып ашаучы юк. Һәркем үз бакчасына утырта. Быел мәйданнарын арттыручылар да бар. Мин үзем дә бәрәңге чәчү мәйданнарын зурайттым. Буш яткан бакчаларга малларга азык чөгендере һәм кабак та чәчтем. Чөнки, беренчедән, терлек санын арттырдым, икенчедән, елның ничек киләсен алдан белеп булмый бит. Узган ел коры булгач, уңыш бик начар булды. Шуңа күрә җитәрлек булсын, дип тырыштым.

Николай Морозов әйтүенчә, боларга өстәп, малларга ашатыр өчен, вак бәрәңгене авылдашларыннан сатып та ала икән. «Сыерларга анысын пешереп ашатам. Кабакны сарык һәм үгезләрне симертер өчен үстерәбез. Кишер, чөгендер уңышы да быел яхшы булырга охшаган», – диде ул.

Аны кая куясы?

Балык Бистәсе районында яшәүчеләр дә бәрәңге уңышына сөенеп туя алмый. Үзләре өчен дип кенә утыртканны сатучылар да бар.

– Әтиләрнең уңышы бик мул булды. Ул кадәрле бәрәңгене кая куеп бетерергә кирәк? – ди Балык Бистәсендә яшәүче Нияз Шәйхетдиновның кызы Ләйлә. – Яңгырлар яхшы яуды бездә. Узган ел да, күпчелек кешедә булмаганда да, кешеләргә саттык. Ләкин тагын да күбрәк сатасы калган дибез, чөнки базда иске бәрәңге һаман да бар.

Ләйлә үзе Казанда яши. Теләүчеләргә бәрәңгене китереп бирәләр икән. Килограммын 25 сумнан саталар.

– Кичә ике капчык алып килгән идем, сатылып бетте. Әти ял көне үзе сатарга килә. Узган елга кадәр сатканыбыз булмады, күрше-күлән, туган-тумачага таратып бетерә торган идек, – диде ул.

«Бәрәңге җитә»

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы мәгълүматлары буенча, быел республикада бәрәңге һәм яшелчә мәйданнары 20 процентка арттырылды һәм ул 7200 гектар тәшкил итә. Шуның 4600 гектарында бәрәңге һәм 2600 гектарында яшелчә үстерелә. Монда әле халыкның йорт яннарындагы мәйданнар исәпкә алынмаган.

– Узган ел халык бәрәңге белән тулысынча тәэмин ителде. Быел да шулай ук булачак. Бәрәңге һәркемгә җитәчәк. Ә менә яшелчә белән тәэмин ителеш моңа кадәр 60–65 процент иде. Быел бу сан 70 процентка якынлашыр дип өметләнәбез, – диделәр министрлыкта.

Сүз уңаеннан, быел да Казанның 15 мәйданында һәм республиканың зур шәһәрләрендә авыл хезмәтчәннәре халыкка үзләре җитештергән продукцияне тәкъдим итәчәк. Беренче ярминкә исә 10 сентябрьдә узачак.

Исегезгә төшерәбез: быел яшелчә үстерүче барлык җитештерүчеләр гектарына 25 мең сум ярдәм алачак. Ә игү мәйданнарын узган ел белән чагыштырганда 10 процент һәм аннан да күбрәккә арттырган хуҗалыкларга һәр гектарына 40 мең сум күләмендә субсидия биреләчәк. (2021 елда мондый ярдәм күләме гектарына 25 мең сум иде. – **Авт.**) Республикада исә яшелчәчелек белән ныклап торып шөгыльләнүче хуҗалыклар бармак белән генә санарлык. Алар арасында иң зурлары – «Кырлай» агрофирмасы, «Бөреле» хуҗалыгы, Нәсим Дәүләтов, Минталип Миннеханов, Владимир Аппаков фермер-хуҗалыклары, «Вятские Зори» җәмгыяте.

Эре хуҗалыкларда бәрәңге уңышы ничек соң? Тукай районының «Бердәмлек» кооперативы җитәкчесе, фермер Минталип Миннеханов әйтүенчә, әлегә хуҗалык бәрәңге алуга керешмәгән. Тик тикшереп, сынап карагач, уңыш уртача, дип бәяләде. Әлеге кооператив республиканың көньяк-көнчыгыш районнарындагы (Тукай, Зәй, Лениногорск, Азнакай, Бөгелмә, Әлмәт) мәгариф һәм сәламәтлек саклау оешмаларын яшелчә белән тәэмин итә.

– Мәктәп, балалар бакчасы, сәламәтлек саклау учреждениеләренә кишер, чөгендер һәм бәрәңге кирәк. Бәрәңгене 80 гектар мәйданда утыртабыз. Аны бик эре дип әйтә алмыйм, әмма безнең өчен анысы мөһим дә түгел. Аларның уртача, бер зурлыкта булуы кирәк, чөнки эре бәрәңге бәрелеп, зыян килә. Шуңа күрә махсус Гала сортын үстерәбез. Аның күзләре тирән түгел, – ди Минталип Миннеханов. – Без балаларга ризык әзерлибез дип, үзебезгә артык мәшәкать тудырабыз. Фураларга төяп озатсак, уңайлырак булыр иде анысы. Тик эш анда түгел. Җитештергән ризыгыбыз Татарстан балалары өчен булсын, дип тырышабыз.

Фермер әйтүенчә, быел эре хуҗалыклар бәрәңгене 20–25 сумнан сатарга ниятләп тора. Чөгендерне исә әлегә 20 сумнан җибәргәннәр.

Тәҗрибәле фермер яшелчәләрне алу, саклау буенча киңәшләрен дә җиткерде.

– Кишер, чөгендер салкынрак һава торышында алынырга тиеш. Шулай булганда ул яхшы саклана. Халык уңышын ала башлады инде, чөнки алар үзләре өчен утырта бит. Күләме дә күп түгел. Мин һәрвакыт халыкка бәрәңге базларын, подвалларын төтен шашкалары белән яхшы итеп әзерләргә киңәш итәм. Вентиляция дә яхшы булырга тиеш. Аннан соң яшелчәләрне аерым-аерым бүлекләрдә сакларга кирәк. Чөгендер – бер, бәрәңге – икенче, кишер өченче бүлектә сакланырга тиеш. Бәя кыйммәт булмасын өчен үзебезгә күпләп утыртырга кирәк, – диде ул.

Минталип Миннеханов әйтүенчә, бәрәңге чәчәккә бөреләнеп, сабаклары саргая башлап көйгәнчегә кадәр үсә. Бакча 80 процент саргайса, бәрәңге сабагын чабып алырга кирәк, ди ул. Казыганчы 10 көнләп тотсагыз яхшы, чөнки сабагыннан өзелгән бәрәңге бу вакыт эчендә ныгып бетә һәм андый бәрәңгедән инфекцияләр дә юкка чыга.

– Өлгерешкә килгәндә, ул бәрәңгенең сортына бәйле, – ди ул. – Хәтта 45 көндә ашарлык булып өлгерә торган бәрәңге бар. Ләкин ул бик тәмле булмый. Кышка саклар өчен уртача һәм соң өлгерә торган сортларны сайлыйлар. Май башында утырткан бәрәңгеләр алырлык булып өлгерде инде хәзер.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БӘРӘҢГЕ УҢЫШЫ НИЧЕК?

Илсум САДЫЙКОВ (Арча районы Утар Аты авылы):
– Узган атнада бәрәңгене ала башладык. Уңыш яхшы чыга. Узган ел начар булгач, кәеф төшкән иде. Быел шөкер итә торган булды, дип куанабыз.

Наилә МӨХӘММӘТҖАНОВА (Мөслим районы):
– Районда бәрәңге ала башладылар. Уңыш төрле кешедә төрлечә дип әйтәләр. Мөслимнең үзендә яшәүчеләр зарланмый. Ә менә авылларда начар. Әниләрнең бәрәңге сабагы кибеп, корып бетте инде. Уңышы да, узган елгы кебек, бик начар. Күпчелек кеше шулай дип зарлана. Су сибеп үстерүчеләрнеке генә шәп, ахрысы.

Гөлназ ГЫЙЛӘҖЕВА (Мамадыш районы Баскан авылы):
– Узган ел белән чагыштырганда, быел бәрәңге вак. Эре дигәннәре юк диярлек. Барысы да уртача зурлыкта. Сакларга өчкә аерып куйдык: вак, симәнәлек һәм ашар өчен.

Эльвира МОЗАФФАРОВА (Яшел Үзән районы Акъегет авылы):
– Узган атнада дәү әнинең бакчасында бәрәңге алдык. Май бәйрәмнәрендә утырткан идек. Гадәттә августның соңгы көннәрендә урнаштыра идек, быел эшләрне иртәрәк тәмамладык. Быел үзенчәлекле ел булды – бик эссе иде. Беренче тапкыр 34 градус эсседә бәрәңге алдык. Бәрәңге пешмәсә ярар иде, дип тә борчылдык. Шуңа күрә өстен дә алдан чабып куймадык. Алган берен сортларга аерып, базга урнаштыра да бардык. Безнең баз бик күптәнге, таш, бик салкын. Шуңа күрә анда бәрәңге яхшы саклана. Уңышка килгәндә, елына күрә яхшы. Ләкин бик шәп дип әйтә алмыйм. Кама Тамагы районында яшәүче каенаналар да уңыштан канәгать. Узган ел тирес керткән идек, шуның да файдасы булды.

9 сентябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Фәния ӘХМӘТҖАНОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Фатир әләгерме?

Социаль ипотекага чиратка баскан идек. Инде фатир сайларга мөмкинлек бирделәр. Әлегә яши торган йортыбыз янәшәсендә «М-14» торак микрорайоны төзелә. Шундагы фатирларны сайламакчы булам да, тик компьютер мөмкинлек бирми. Ул фатирлар кемнәргә икән?

Раилә МОРТАЗИНА. Казан

Татарстан Президенты каршындагы Дәүләт торак фондының матбугат сәркатибе Гөлзада Кычакова:
– «М-14»тәге йортлар быел тапшырылмаячак. Ул икенче елга гына әзер була. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, ул фатирлар иң беренче чиратта табибларга һәм укытучыларга биреләчәк, диде. Әгәр сез башка һөнәр иясе икән, «Салават Күпере»ндә булган буш фатирларга өметләнә аласыз.

Нинди ярдәм бар?

Мин – өйләнмәгән егет. Армиядән кайтып, эшкә урнашуыма – ярты ел. Шәһәр җирендә яшьләргә социаль ипотекадан тыш, нинди программа буенча торак алырга мөмкин?

ФӘННУР. Казан

Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгының матбугат хезмәте:
– Яшьләр эшләре министрлыгы программалары арасында республикадагы яшьләр сәясәте лидерлары өчен махсус социаль ипотека программасы бар. Ул конкурс тәртибендә бирелә. Конкурста 18–30 яшьлек кешеләр катнаша ала. Ләкин аларның республикада мәгариф һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсендә эшләве яки иҗтимагый эшчәнлек алып баруы зарур. Әлеге социаль ипотека төрле иҗтимагый оешмалар активистлары, актив студентлар, яшь галимнәргә бирелә. Әлеге конкурсның тулырак шартлары белән безнең министрлыкның рәсми сайтында танышып була.



«ВТ» архивыннан

Балам өчен салым кайтарып буламы?

Кызым түләүле бүлеккә укырга керде. Укыганда түләгән акчадан салым чигерүе кайтырып була дип ишеткән идем. Аның өчен кая барасы? Нинди документлар кирәк икән? Ул көндезге бүлектә укыган балалар өчен генәме? Әллә инде читтән торып укучылар да акча кайтара аламы?

Гөлсинә ФӘРХИЕВА. Казан

Казан шәһәренең 6 нчы салым инспекциясе баш белгече Рәмзия Мөхетдинова:
– Һәркем белем алганы өчен тотылган акчаның 13 процентын кайтарырга хокуклы. Түләүле мәктәпләр, чит телләргә өйрәтә торган курслар, машина таныклыгы алу өчен автомәктәптә уку, квалификацияне күтәрү өчен белемне арттыру, балалар өчен спорт секцияләре, музыка, сәнгать мәктәпләре, төрле түгәрәкләр өчен тотылган чыгымнарның 13 процентын кайтарырга була. Моның өчен әлеге белем бирү оешмаларының лицензиясе һәм сезнең алар белән килешү төзелгән булырга тиеш.

Укыган өчен түләгән акчаның 13 процентын һәр елны кайтарып алып була. Әгәр инде кеше ахыргы курста укый һәм бер тапкыр да салым кайтармаган икән, бу очракта соңгы өч елга гына акчаны кайтара аласыз. Тагын бер шарты бар – салым акчасын көндезге бүлектә укучылар гына кайтара ала. Моның өчен уку йорты белән килешү, белем бирү оешмасының лицензиясенең күчермәсе, укыган өчен түләгәнлеккә квитанция, 2-НДФЛ белешмәсе, паспорт, 3-НДФЛ формасы буенча салым декларациясе, банкта ачылган исәп счеты, шул банкның реквизитлары кирәк булачак.

Укучы сүзе

«ИШЕЛМӘСЕН ТАУЛАР» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Шушы кадәр гамьсезлек эшләргә кемнең башы җитте икән?! Быелга кадәр дә тау итәгенең балчыгын ташый башлаганнар иде инде. Чаукә тавы кырыеннан узганда күзгә яшьләр килә. Гасырларның тарихын үз эченә сыендырган горур тау хәзерге көндә яраланган, ләкин сыгылмаган солдат кебек басып тора. Табигатькә кешеләрнең ваемсызлыгы аркасында зыян килү – корылыкның сәбәбедер. Чаукә тауга ябышмасалар ярамаганмы инде. Беткәнме башка җирдә кызыл балчык? Кешеләр аркасында киләчәк булмаска да бик мөмкин. Табигать үз җавабын кайтарыр ул.

Зөлфия УСМАНОВА-СӨЛӘЙМАНОВА

«ЭТ ЭТЛЕГЕН ИТӘ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

«Колакларына тамга салып чыктылар да, эш бетте. Аннан кемгә файда?» – дигән соравыма бер бәндә: «Кызыл тамга агрессив икәнен күрсәтә», – дип җавап бирде. Шуннан ни? Кичә генә радиодан сөйләделәр: этләр үтерүне закон тыя, кешене таласа да, үтерсә дә, дип. Димәк, сукбай эт гомере кеше гомереннән кадерлерәк, алар илгә күбрәк файда китерә дип саналамы?

Зөһрә ЯРУЛЛИНА

***

Казанның Идел буе районында, көннең кайсы вакытына карамастан, яңа Зоопарк, Архангел зираты, Урта Кабан буен иңләп, 20–25 эт йөри. Бигрәк тә төнге вакытта көтүләре белән йөриләр, мәчеләрне буалар. Бу хәлләргә берәүнең дә исе китми, кешегә генә ташланмасалар ярар иде, дип котлар алынып тора.

Наилә ЗАҺИРОВА

«БЕЗ ХӘЗЕР ЯҢА ӨЙДӘ ЯШИБЕЗ БИТ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Кеше күтәрмәстәй авырлыкны кичергән бу ханымны Раббыбыз ярдәменнән ташламасын. Афәрин, юньле бәндәләр дә бар икән.

Елена ГАРИФУЛЛИНА

***

Җан биргәнгә җүн биргән, диләр… Менә бит күпне күргән Рәйсәнең язмышында да үзгәрешләр булган. Бар да әкренләп, Аллаһы Тәгалә ярдәме белән җайга салынып әле.

Мөнирә ГАРИФУЛЛИНА

Фикер

30 август – Республика көнендә Казанда төрле җирләрдә концертлар булды. «ТНВ» телеканалыннан трансляциясен күрсәтәбез, диделәр. Ачкан идем, урысча сөйләшәләр. Менә сиңа тел үстерү, менә сиңа Республика көне! Алып баручылары татарлар югыйсә, урысча сөйлиләр. Филүс Каһиров чыккач, сүнгән идем. Шунда да аны арткы планда калдырып, алгы планда урысча интервью алдылар. Менә шулай итеп бәйрәм көнне дә Татарстанның төп каналыннан татарча концерт карый алмыйча утырдык.

Чулпан ҺАДИЕВА.
Кукмара районы
Бакча-Сарай авылы

***

Тел үткәнне һәм хәзергене, өлкән һәм киләчәк буыннарны бербөтен итеп саклый. Тел бетсә, халык та бетә. Халыктан нәрсәне генә тартып алсагыз да, ул аны кире кайтара ала. Ә телен алсагыз, ул аны беркайчан да кайтара алмаячак. Җитәкчеләр 2023 елны Укытучы һәм остаз елы дип игълан итте. Шуңа да уку йортларында, беренче чиратта, мәктәпләрдә укытучыларның җаваплылыгы артачак. Җитәкчеләребез туган телне дә игътибарга алса иде. Туган телен кадерләгән халыкның гына кадере була.

Сәгъдулла ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ.
Казан

Ялгыш күчерелгән акчаны куллана аламмы?

Күптән түгел банк картасына шактый гына зур суммада акча килеп төште. Беркайдан берниндинди акча аласым юк иде. Ялгыш күчергәннәрдер дип аңладым. Шул көннән бирле бер атна вакыт узды. Минем белән элемтәгә керүче дә, акчаны кире кайтаруымны сораучы да юк. Миңа хәзер ни эшләргә? Ул акчаны тотсам, нәрсә булыр икән?

АЛСУ. Саба

Юрист Роман Архипов:
– Бер счеттан икенчесенә акча күчергәндә реквизитларда хата киткән булса, моның өчен акча күчерүче җавап тотарга тиеш. Монда карта хуҗасының бер гаебе дә юк. Ялгыш күчерелгән акчаны кире кайтарып була. Әмма моның өчен шактый вакыт таләп ителә. Монысы – акча күчерүче колагына әйтелгән сүзләр. Сезнең очракта, әгәр дә сез картагызга ялгышлык белән күчерелгән акчаны туздырырга уйлыйсыз икән – мең кат үкенергә туры киләчәк.

Картагызга ялгыш акча күчергәннәр икән, бу хакта кичекмәстән банкка шалтыратып хәбәр итәргә кирәк. Башкача сездән берни таләп ителми. Бу хәлгә банк үзе ачыклык кертергә тиеш. Әгәр сез шушы көтелмәгән акчаның бер өлешен туздырып өлгергән булсагыз, бу чит акчаны үзләштерү дип саналачак. Банк сездән тотылган акчаны да кайтаруны таләп итәчәк. Каршы килсәгез, сезне судка да бирә алалар. Суд банк файдасына карар чыгарса, карта хуҗасына карата Җинаять кодексының 159 нчы («Мошенниклык») һәм 160 нчы («Үзләштерү һәм туздыру») маддәләре нигезендә җинаять эше ачылырга мөмкин.

Әгәр карта хуҗасы көтелмәгән акча килеп төшүе турында банкка хәбәр итмәсә, акчаны кире кайтаруны сорап мөрәҗәгать итүче дә булмаса, шикаять срогы тәмамлануга, ул бу акчаны тота ала. Россия Гражданлык кодексының 196 нчы маддәсе нигезендә моны бу вакыйгадан соң өч ел вакыт үткәч кенә эшләргә мөмкин. Әмма шунысына да әзер торыгыз: сезгә ялгыш акча күчергән кеше еллар үткәч тә пәйда булырга мөмкин. Әгәр ул үзенең җитди сәбәп аркасында акчасын вакытында кайтара алмавын дәлилли алса, сезне җаваплылыкка тартырга мөмкиннәр.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

5 сентябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 16.00 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
17.00 «Татарлар» 12+
17.30 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Ак барс». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3». Телесериал 12+
23.50 «Каравай». Сад памяти. Цветы и травы Каюма Насыри 6+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Ком сәгате» 12+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Рәдиф Гаташ турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Яңалыклар» 12+
23.05 «Башваткыч» 12+
00.00 «Яңалыклар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА» (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 12+
02.50 Ярослав Бойко, Ольга Погодина. «СРОЧНО В НОМЕР!» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.15, 12.35, 15.30 Новости
06.05, 21.15, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.20, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.40 «ЗАГОВОРЁННЫЙ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «ЛУЧШИЕ ИЗ ЛУЧШИХ» 16+
15.05, 15.35 «ЗАБОЙНЫЙ РЕВАНШ» 16+
17.25 «Громко»
18.30 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. ЦСКА – «Ак барс» (Казань). Прямая трансляция
21.40 Футбол. Чемпионат Италии. «Торино» – «Лечче». Прямая трансляция
00.35 Тотальный футбол 12+
01.05 Всероссийская спартакиада по летним видам спорта. Баскетбол. Женщины. Финал 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Наши иностранцы» 12+
03.25 «ЭЛАСТИКО» 12+
05.05 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Остросюжетный сериал «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ» (S) 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.45 Остросюжетный сериал «МЕНТ В ЗАКОНЕ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Свечная тьма» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.00 «МОЯ ЛЮБИМАЯ МИШЕНЬ» 16+
19.00 «ГДЕ ЖИВЁТ НАДЕЖДА?» 16+
22.50 «Порча». «В огне» 16+
00.00 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.55 «Тест на отцовство» 16+
03.35 «Давай разведёмся!» 16+
04.25 «Преступления страсти» 16+
05.15 «6 кадров» 16+
05.30 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

03.30 «ПРИ ЗАГАДОЧНЫХ ОБСТОЯТЕЛЬСТВАХ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.20 «МОРЕ СТУДЕНОЕ» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.35 «Сделано в СССР» 12+
13.50, 14.05 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+
14.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Освобождение Европы». Док. сериал. «От Буга до Одера». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Док. сериал. «Виктор Луи. Личный агент Андропова» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 16+
01.00 «ТРОЕ ВЫШЛИ ИЗ ЛЕСА» 16+
02.30 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа». Док. фильм 16+
03.25 «Перелом. Хроника Победы» 16+
03.50 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ» 16+

6 сентябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА 3» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БЕРЕНЧЕ НОМЕРЛЫ ГАСТРОНОМ ЭШЕ». (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Карл Фукс, которого любили все 12+
00.40 «Каравай». Виртуоз-баянист Динар Бадрутдинов 6+
01.05 «Уроки истории». Татарская национальная идентичность в начале XX века 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
08.40 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30 «Халкым минем» 12+
11.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Галимҗан Ибраһимов турында телеочерк 6+
15.00 «Яңалыклар» 12+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.00 «Яңалыклар» 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА» 16+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Халкым минем» 12+
21.00 «Яңалыклар» 12+
23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
00.00 «Яңалыклар» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
04.15 «Җырлыйк әле!» 6+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 «ЗОЛОТАЯ ОРДА». Многосерийный фильм (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. «ЕЛИЗАВЕТА» 12+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «МОРОЗОВА» 12+
02.50 «СРОЧНО В НОМЕР!» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.15, 12.35, 15.30, 18.40 Новости
06.05, 15.35, 18.45, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.20, 12.40 Специальный репортаж 12+
09.40 «ЗАГОВОРЁННЫЙ» 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.00 «ЛУЧШИЕ ИЗ ЛУЧШИХ 2» 16+
15.05 Матч! Парад 16+
16.15 «ОРУЖЕЙНЫЙ БАРОН» 16+
19.30 Футбол. Лига чемпионов. «Динамо» (Загреб, Хорватия) – «Челси» (Англия). Прямая трансляция
21.45 Футбол. Лига чемпионов. ПСЖ (Франция) – «Ювентус» (Италия). Прямая трансляция
00.55 Футбол. Лига чемпионов. «Севилья» (Испания) – «Манчестер Сити» (Англия) 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «Правила игры» 12+
03.25 Футбол. Кубок Либертадорес. 1/2 финала. «Палмейрас» (Бразилия) – «Атлетико Паранаэнсе» (Бразилия). Прямая трансляция
05.30 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. Обзор тура 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «КАНЦЕЛЯРСКАЯ КРЫСА. БОЛЬШОЙ ПЕРЕДЕЛ» (S) 16+
21.40 Премьера. Остросюжетный сериал «РИКОШЕТ» (S) 16+
00.00 «ПЁС» (S) 16+
01.50 «МЕНТ В ЗАКОНЕ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.15 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». «Пилигрим» 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.00 «МОЯ ЧУЖАЯ ДОЧКА» 16+
19.00 «ПРИДУМАННОЕ СЧАСТЬЕ» 16+
23.00 «Порча». «Голоса» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.40 «Верну любимого» 16+
01.10 «Понять. Простить» 16+
02.05 «Тест на отцовство» 16+
03.45 «Давай разведёмся!» 16+
04.35 «Преступления страсти» 16+
05.25 «6 кадров» 16+
05.35 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15 «СМЕРШ. ЛЕГЕНДА ДЛЯ ПРЕДАТЕЛЯ». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 16+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.20 «ТАЕЖНАЯ ПОВЕСТЬ» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.25 «Не факт!» 12+
14.00 Военные новости 16+
14.05 «СНАЙПЕР. ОФИЦЕР СМЕРШ». 1-я – 4-я серии 16+
18.15 «Специальный репортаж». 16+
18.50 «Освобождение Европы». Док. сериал. «Пражский прорыв». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого». «Пластическая хирургия под грифом «секретно» 16+
22.55 «Между тем» 16+
01.05 «ПРАВДА ЛЕЙТЕНАНТА КЛИМОВА» 12+
02.30 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 16+
04.00 «НЕ ЗАБЫВАЙ». 1-я и 2-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур бүлекчәсе «Лениногорскнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе нефть һәм газ чыгару операторы **Минязев** Дилбәр Шәһит улына **«Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ чыгару сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күпьеллык намуслы хезмәте өчен Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры каршындагы башкарма аппаратның икътисади идарә начальнигы **Гайфуллина** Резедә Рәүф кызына **«Россия Федерациясенең атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Социаль әһәмияткә ия объектлар төзүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Казилов** Владимир Александрович **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Мәгълүмат технологияләре тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ИТ-парк» югары технологияләр өлкәсендәге технопаркы» дәүләт автоном учреждениесе башкарма директоры **Власов** Руслан Игоревич; республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Евростройхолдинг+» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең төзелеш буенча директоры **Насыйров** Руслан Рафаил улы; «Реконструкция һәм Үсеш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Сидоров** Алексей Викторович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен **Калинкина** Анна Павловна **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының «Татинвестгражданпроект» баш территориаль проект-тикшеренү фәнни-җитештерү фирмасы» дәүләт унитар предприятиесенең 6 номерлы архитектура-планлаштыру остаханәсе башлыгы **Сидоров** Александр Николаевичка **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«7 номерлы төзелеш-монтажлау идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе **Әхсәнов** Ришат Азат улына, «Территорияләрне үстерү фонды» хокук эшләре гавами компаниясенең «Төбәкләрне үстерү» бүлекчәсе юнәлеше җитәкчесе **Әхмәтханов** Айрат Рәфкать улына, «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү цехының авариядән соң торгызу эшләре слесаре **Буханов** Иван Михайловичка, «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 3 нче арматура цехының арматура челтәрләре һәм каркаслар эретеп ябыштыручысы **Попов** Алексей Владимировичка, «Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте 24 нче калыпка салу цехының калыпка салу агрегаты машинисты **Ситдыйков** Илдар Хәсән улына, «Агропак-Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры урынбасары **Галиева** Динә Дәүләтбай кызына, «Агропак-Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең азык-төлек сәнәгате җитештерүендә линия операторы **Шакирова** Гүзәл Зәет кызына, Татарстан Республикасының «Шәһәр яны урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе җитәкче-урманчысы **Кашафиев** Илнур Рафаэль улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының социаль үсеш буенча урынбасары **Мөхәммәдиев** Рөстәм Нәбиулла улына, «Проект МНК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте баш инженеры **Ожередов** Евгений Витальевичка, «Геология, эзләү-тикшеренү үзәге» акционерлык җәмгыяте баш геологы **Прокофьев** Роман Владимировичка; «Электросоединитель» акционерлык җәмгыяте генераль директорының җитештерү һәм сату буенча урынбасары **Шәйдуллин** Назиф Фәез улына, **«Агропак-Татарстан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Домкор Индустрия» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте коллективына**, **«Татарстан Республикасында Стандартлаштыру, метрология һәм сынаулар дәүләт төбәк үзәге» федераль бюджет учреждениесе коллективына, «Татарстанның элиталы орлыклары» бөртекле культуралар орлыклары җитештерү ассоциациясе коллективына**, «Әюпов Рамил Миргалим улы» крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы **Әюпов** Рамил Миргалим улына, «Закирова Ландыш Әхәт кызы» крестьян (фермер) хуҗалыгы бухгалтеры **Закиров** Риф Сабирҗан улына, «Татнефть-АЗС-Төньяк-Көнбатыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Хәбибуллин** Айдар Нурмөхәммәт улына, «Чистай җылылык челтәрләре предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Харисов** Марат Әсхәт улына, Зеленодольск муниципаль районының «Район координация-методик мәдәният үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директорының иҗат буенча урынбасары **Бечин** Дмитрий Анатольевичка, Уфа «Нур» дәүләт татар театры дәүләт бюджет мәдәният һәм сәнгать учреждениесе драма артисты **Биктимерова** Гөлназ Тимерҗан кызына, Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районы «Юхмачы гомуми урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директорының укыту-тәрбия эше буенча урынбасары **Букарцева** Светлана Алексеевнага, «Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернат» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы (Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы) **Шәрипова** Чулпан Рәмзил кызына, «Бөтенроссия дәүләт юстиция университетының (Россия Юстиция министрлыгының Россия хокук академиясе)» Казан институты (филиалы) юридик факультеты деканы **Гәрәев** Илнур Габделхак улына, «Агыйдел» җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең сәнгать җитәкчесе **Фәтхуллина** Лилия Равил кызына, Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе башлыгы урынбасары **Фатыйхов** Линар Замир улына, Мөселман эшкуарлар ассоциациясе президенты **Шаһимәрдәнов** Айдар Равил улына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының «Филология һәм мәдәният» һәм «Tatarica» журналлары редакциясе әйдәүче мөхәррире **Хәбетдинова** Миләүшә Мөхәммәтҗан кызына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте** белдерелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ЕЛАП ТҮГЕЛ, ҖЫРЛАП УЗСЫН

Табигатьнең алтын, мул чорына аяк бастык. Әбиләр чуагы, уңыш җыю, кышка әзерлек кебек күңелле мизгелләр белән узучы көз еш кына күңел төшенкелеге белән дә истә кала. Көзге депрессиягә бирешмәүнең сере нидә? Алтын ел фасылын елап түгел, җырлап уздырыр өчен нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-психиатр, психотерапевт, медицина фәннәре кандидаты Гүзәл ГЫЙЛАҖИЕВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Ни өчен көз һәм депрессия аерылгысыз төшенчәләр?
– Фәндә көзге депрессия дигән төшенчә юк. Көзге чорда күңел төшенкелегенә бирелүчеләр саны бермә-бер арта. Халык телендә мондый төшенчәнең пәйда булуы әнә шуңа бәйле. Көзгә таба кешегә яктылык, җылылык җитми башлый. Өстәвенә бу чорда эштә, гаиләдә дә проблемалар башланса, күңел төшенкелегенә бирелерә күп кирәкми.

:: Кешенең депрессиядә икәнен нинди билгеләр буенча ачыкларга?
– Көзге күңел төшенкелегенә бирелгән кешенең кәефе булмый, ул ярсучанга әйләнә, аның даими рәвештә йоклыйсы килә. Ул кисәк кенә ябыгырга яки киресенчә, артык килограммнар җыярга мөмкин. Кешеләр белән аралашасы, күрешәсе килмәү, уку, эшләү, хуҗалык эшләрен башкару өчен хәл дә, теләк тә булмау шулай ук күңел төшенкелегенең бер билгесе булырга мөмкин. Әгәр кем дигәндә ике атна дәвамында алда телгә алган билгеләрнең берсе генә булса күзәтелсә дә, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Бу очракта йокы режимы да бик зур роль уйный. Депрессия вакытында кеше йокысызлыктан интегә, тынгысыз йоклый яки, киресенчә, көн дәвамында йоклый. Кеше үзенең депрессиягә бирелгәнме-юкмы икәнлеген Бек тесты узып та ачыклый ала. Аны интернетта табарга мөмкин. Дөрес, алда телгә алган билгеләр күңел төшенкелегеннән тыш, күп кенә башка чирләр турында да кисәтергә мөмкин. Шуңа күрә төгәл диагнозны табиб-психиатр яки психотерапевт куярга тиеш.

:: Депрессиядән дәваланырга кирәкме?
– Әлбәттә. Вакытында чарасын күрмәсәң, кешенең хәле тагын да авыраерга мөмкин. Әмма бу депрессия ниндидер башка чиргә әверелачәк дигән сүз түгел. Ул организмда параллель рәвештә башка авыруларның пәйда булуына китерә ала. Әйтик, кеше кәефен күтәрү өчен шешәгә үрелергә, йокысызлыктан котылу өчен даруларга ияләшергә мөмкин. Күңел төшенкелеге артык авырлык, эш урынында мәшәкатьләр китереп чыгарырга, якыннар белән мөнәсәбәтләрнең бозылуына да китерә ала.

:: Көзге депрессиягә балалар да бирешә аламы?
– Күңел төшенкелегенең яше юк. Аңа өлкәннәр генә түгел, балалар да, үсмерләр дә бирешә ала. Өстәвенә көзен мәктәптә укулар башлана, баланың тормышында да мәшәкатьләр арта. Ул мондый үзгәрешләргә әзер булмаска мөмкин. Сыйныфташлары белән аралашканда кыенлыкларның да булуы ихтимал. Шуңа күрә ата-анага бу чорда баласына карата аеруча игътибарлы булырга кирәк. Баланың уку белән ялын да дөрес итеп көйләү мөһим. Аны юкка-барга гаепләү, тәнкыйтьләүдән дә сакланыгыз. Үз кичерешләрен генә кичмәсә, балалар психологына да мөрәҗәгать итсәгез була.

:: Коронавирус белән авырган кешеләр арасында да күңел төшенкелегенә бирешүчеләр шактый бит...
– Әйе, күптән түгел уздырылган тикшеренүләр ковид белән авырып терелгәннән соң еш кына күңел төшенкелеге күзәтелүен раслый. Төп билгеләре, дәвалау алымнары буенча әлеге депрессия башка төр депрессияләрдән аерылмый. Шуңа күрә коронавирус белән авырып терелгәннән соң да психиатр яки психотерапевтка күренү зыян итмәс.

Идар Мөхәммәтҗанов

КӨЗГЕ ДЕПРЕССИЯДӘН НИЧЕК КОТЫЛЫРГА?
✓Кояшлы көннәрдә күбрәк урамда йөрергә тырышыгыз. Бүлмәдә дә яктылык җитәрлек булсын. 18 квадрат метрлы бүлмәдә үзеңне яхшы хис итү өчен яктылык 250 ваттан да ким булмаска тиеш.
✓Ял белән эшне дөрес оештырыгыз. Тәүлегенә кимендә җиде-сигез сәгать йокларга кирәген дә онытмагыз.
✓Дөрес туклангыз. Составында D һәм E витаминнары булган фундук, арахис чикләвекләре, карабодай, сөт ризыклары, шулай ук балык, яшелчәләр, җиләк-җимеш, шоколад ашау файдалы.
✓Яраткан эшегез белән шөгыльләнегез. Галимнәр, физик күнегүләр ясаганда шатлык гормоннары бүленеп чыга, дип ышандыра. Дусларыгыз, туганнарыгыз белән аралашырга вакыт табыгыз. Киного, театрга, кунакка йөрү дә кәефне күтәрә. Фастфуд, ярымфабрикатлар, чипсы, кызган ашамлыклар исә – начар кәеф чыганагы.
✓Көзнең матурлыгын да күрә белергә кирәк. Сары яфраклар җиргә түшәлгән чорда матур фотосессия ясап алу да күңел төшенкелегенә бирешергә ирек бирмәс.

:: Кояш төсе – сары төстәге җиләк-җимеш, чәчкәләр депрессиядән коткара, дигән фикер яши. Бу сүзләр ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килә?
– Юк, бу сүзләр дөреслеккә туры килми. Дөрес туклану, әйтик, шул ук яшелчә, җиләк-җимешләргә өстенлек биреп, күңел төшенкелеген кисәтеп була әле. Әмма сары төстәге әйберләр генә депрессиядән коткара алмый.

:: Күңел төшенкелегеннән үзлегеңнән генә котылып буламы?
– Бу очракта белгеч ярдәменнән башка булмый. Чирне алдан кисәтү хәерлерәк. Күңел төшенкелегенә бирешмәс өчен йокы туйганчы йокларга, дөрес итеп тукланырга, исерткеч эчемлекләр кулланмаска, стресслардан ерак торырга, үзеңнең психик халәтеңне даими рәвештә контрольдә тотарга кирәк. Кояш нурларына бәйле кешеләр көзге моңсу көннәр өчен таң атуны хәтерләткән махсус уяткыч сәгать алып куя ала. Без яшәгән җирлектә кояшлы көннәр бик аз. Шуңа күрә Д витамины да эчәргә кирәк.

Сентябрьдә җыела торган файдалы үләннәр һәм җимешләр

Гөлҗимеш. С витаминына бик бай. Салкын тигәндә, грипп, кан басымы, кан тамырлары авыруларыннан бик файдалы. Кипкән гөлҗимештән бик тәмле һәм хуш исле чәй ясап була.

Миләш. Иммунитетны ныгыта. Миләштә А витамины бик күп. Күз күрүе өчен аеруча яхшы. Миләштә нерв системасын ныгытучы ярдәм итүче, стресслардан саклаучы, йокыны яхшыртучы В төркеме витаминнары бар. Миләш канның оючанлыгын яхшырта.

Нарат җиләге яфрагы. Антисептик һәм бактерияләргә каршы тору үзенчәлегенә ия. Организмны ныгыту өчен салкын тигәндә эчәләр. Нарат җиләге яфрагының чәе картаю процессын тоткарлый, хатын-кызларга гормоннарны җайларга булыша.

Бөтнек. Бөтнек чәе нерв системасын җайга сала, хәтерне яхшырта, игътибарлы тупларга ярдәм итә. Кипкән бөтнекне кечкенә савытка салып, хуш ис тарату өчен аш бүлмәсендә дә сакларга була. Бөтнекне чәйгә генә түгел, камыр ашларына һәм смузиларга да кушалар.

Әрекмән тамыры. Әрекмәннең яшь тамырын казып алалар һәм юалар. Әлеге үсемлек тамырында протеиннар, эфир майлары, B, C, E, A, P витаминнары, дуплау матдәләре, минераль тозлар, органик кислоталар бар. Аны матдәләр алмашы бозылганда, бөергә таш утырганда файдаланалар.

Гемоглобинны күтәрәбез

●Бер үк күләмдә яңа сыгылган кара торма, кишер, кызыл чөгендер, гранат соклары алып, барысын бергә болгатыгыз. Банкага бушатып, өстен каплап, 3 сәгать җылы духовкада тәнәтегез дә, суынгач, сөзегез.
●1әр аш кашыгы вакланган миләш һәм гөлҗимешкә ике стакан кайнар су агызып, шуны сүрән утта 5 минут кайнатасы. Савытны калын сөлге белән төреп, бер тәүлек тоткач, сөзәргә кирәк. Аз гына бал салырга да була. Төнәтмәне көнгә 3–4 мәртәбә ашар алдыннан яртышар стакан эчәләр.
●300әр грамм күрәгә, йөзем, караҗимеш, инҗир, кабыклы 2 лимонны (төшләрен алырга) иттарткыч аша чыгарасы да, тәмәнә карап, бал салырга, барысын бергә яхшылап болгатырга кирәк. Катнашманы пыяла банкада суыткычта саклыйсы. Шуны көнгә 3–4 тапкыр 1әр аш кашыгы эчәргә.

Абау!

Краб таякчыклары файдалы ризык түгел. Бөекбритания галимнәре шулай дип ышандыра. «Бу таякчыкларның 25–45 процентын «суриме» балык фаршы тәшкил итә. Калганы – крахмал, йомырка агы, үсемлек мае һәм стабилизаторлар. Төсе матуррак булсын өчен аңа әле төрле буяу, тәмләткечләр дә кушыла», – ди алар. Белгечләр краб таякчыгының сыйфатын тикшерү өчен аны салфетка белән сөртеп карарга киңәш итә. Салфетка алсу төскә керә икән, димәк, монда буяулар бар. Дөрес сакламаганда анда куркыныч бактерияләр үрчи башлый.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Гөлнара
ЗИННӘТУЛЛИНА

КӨЗГЕ ЭШ ЕЛ ТУЙДЫРА

vk.com

Яшелчә, җиләк-җимешләрнең күбесе җыелган, банкалар ябылган, бакчаны ямьләп утырган чәчәкләрнең күбесе сулган... Тик, җәй бетте дип, ямансулап утырыр вакыт түгел. Чөнки көзнең беренче аенда да бакчада эш җитәрлек. Аларны соңга калмый эшләп кую – киләсе ел уңышына нигез салу, ди һәвәскәр бакчачы Гөлфия Хәнипова. Ул хәзердән дә соңга калмый бакчада башкарырга кирәкле эшләр хакында искә төшерде.

Җыю. Көзен алма, груша, сливаның соң өлгерә торган сортлары һәм миләш җыела. Уңышны аскы ботаклардан өскә таба җыя башларга кирәклеген искәртеп тору кирәкмидер. Соңга калып өлгерә торган сортлар кышка саклау өчен яхшы. Шуңа саклау урыны һәм чаралары турында кайгырта башларга вакыт.

Куак һәм агач төпләрен ашлау. Җимеш бирә торган агач һәм куак төпләрендәге туфрак ярлылана, аны кичекмәстән тулыландырырга кирәк. Көзен агачлар яфрак үстереп, кабат ботаклар җибәреп, көчен үсүгә сарыф итмәсен өчен азотлы ашламалар кертмәскә, ә калий һәм фосфорлыларга өстенлек бирергә киңәш ителә. Бу очракта көзге дип саналган көл, суперфосфат, күкертле, хлорлы ашламалар куллану яхшы.

Корткычларга каршы көрәшү. Уңыш җыю сезоны бетте дип, корткычларга каршы көрәшне туктатмыйбыз. Агач-куакларның яфраклары коелганчы, ә корткыч бөҗәкләр туфракка качып өлгергәнче «Актара», «Инта-Вир» яки шуларның аналогы булган препаратлар белән эшкәртергә кирәк. Әлеге эшне соңга калдырырга ярамый, чөнки корткычлар тирәнгә – туфракка качып өлгергәннән соң, агулап торуның файдасы юк. Яфраклар коелгач корткычларга каршы башка чаралар кулланырга кирәк була.

Чүп үләннәрдән арындыру. Кура һәм бакча җиләге тирәсе әйләнәсен кышка эшкәртелмәгән килеш калдырмагыз. Алар төбендә калган чүп үләннәр салкыннар башланганчы үсеп үрчергә һәм күбрәк мәйданны басып алырга өлгерәчәк. Чүп үлән тамырларыннан арындырып, туфракны казып, торф яки агач чүбе сибеп калдырсагыз яхшы.

Су сибү. Су сибү сезоны бетте, дияргә ашыкмагыз. Быелгы эссе һәм коры җәйдән соң агач һәм куак төпләренә яхшылап су сибеп калдыру зарур. Агач төбендәге туфракка дым 1–1,5 метр чамасы төшкән булырга тиеш. Моның өчен яшь агачларга – 40 л, зурларына – 50–70 л, ә бик зур агачлар төбенә 100 литрга кадәр су сибү кирәк. Суны агач-куаклардан яфраклар коелып бетә язгач сибәргә киңәш ителә.

Кисү. Агач-куакларны яхшылап карап, корыган яки корый башлаган, авыру һәм зарарланган ботакларын кисегез. Аннары аларны формалаштырып чыксагыз да була. Анысын кыш азагы, яз башына калдырсагыз да ярый. Бакча җиләкләрен тагын бер кат карап чыгарга онытмагыз: соңгы тапкыр мыек һәм авыру яфракларын алып чыгыгыз.

Кураның ремонтант сортлары җимеш биреп бетергәннән соң, аларын да, җәен җиләк биргәннәрен дә кисәргә онытмагыз. Җәйге кураларның карарак булып торган төпләрен алып атыгыз, ә яшьләренең агач сыман нык булган җиренә кадәр очларын кисеп чыгыгыз. Ремонтант кураларны исә төбенә кадәр кисәргә киңәш ителә. Ә иртәрәк җиләк бирсен өчен, берничә түбән кисми калдырып, кышка төреп куярга да мөмкин.

Яшь агач-куаклар утырту. Нәкъ менә хәзер яңа сортлар турында кайгыртып, яшь агач-куаклар утырту өчен дә кулай вакыт. Күптән үстерергә хыялланып йөргән агач-куакларны танышларыгыздан яки питомниклардан алып утырту турында кайгырта башлагыз, алар тамыр ныгытып калырга өлгерәчәк. Утыртканчы ике атна алдан аның өчен урын һәм тукландырылган туфрак әзерләү турында да онытмагыз. Чөнки кая туры килә, шунда утырткан агач-куакларны аннары күчереп йөрергә туры килүе бар.

Акшарлау. Әлеге эшне кыш ахырына калдырганчы, көзен эшләү хәерлерәк. Акшарлау өчен водоэмульсион буяу куллансагыз яхшы. Ул яңгырларда да ансат кына юылмаячак. Шулай ук агачларны капчык яки спанбонд белән дә төрергә була.

Тәмле булсын!

Файдалы салат

Гүзәлия Хәмитова рецепты

Кирәк: эре булмаган 2–3 кыяр, 4 пешкән йомырка, 200 г пешкән тавык ите, 200 г салат яфрагы, 1 данә авокадо, 1 чәй кашыгы ачы булмаган гәрчич, 150 г грек йогырты. Кыяр, йомырка, салат, тавык ите һәм авокадоны шакмаклап турарга һәм бераз тоз сибеп, гәрчич, йогырт белән болгатып табынга бирергә.

Алма белән әфлисун җимы

Рәмзия Әхмәдуллина рецепты

Кирәк: 3 кг алма, 4 данә әфлисун, 3 кг шикәр комы. Алмаларны юып, эчен алып, сулы кәстрүлгә салып пешерергә куябыз. Алмалар тулысынча эреп беткәнче пешерәбез. Шуның өстенә иттарткычның вак тишегеннән чыгарылган әфлисун белән шикәр комын өстәп, кайнатуны дәвам итәбез. Гел болгаткалап торып, 15–20 минут пешерәбез. Сүндереп, кайнар килеш стерильләштерелгән банкаларга тутырып, тимер капкач белән каплыйбыз. Бик тәмле чыга. Аз гына крахмал өстәп, пирог эчлеге итеп тә кулланып була.

Хуҗабикәгә

Тоз сала беләсеңме?

➤Иткә тозны әзер булырга ярты сәгать алдан салсаң, ул йомшаграк була.
➤Бавырга тозны кыздырып бетерер алдыннан гына сибәргә кирәк, чөнки алдан тозлаган очракта ул катып китә. Бераз суган белән каймак та өстәп җибәрсәгез, телегезне йотарсыз!
➤Балыкны кыздырырга табага салганчы 15 минут алдан тозларга кирәк.
➤Бәрәңге изелеп торсын өчен тозын – пешеп чыгар алдыннан, изелмәсен дисәгез, башта ук салырга киңәш ителә.

Исеңдә тот!

Майонезны алыштыра

Соңгы вакытта майонезның зыяны турында гел әйтеп торалар. Бер иәләшкәч, салатларны ансыз күз алдына да китереп булмый. Майонез урынына түбәндәге катнашманы кулланырга була. Каймакка бик яхшылап изелгән пешкән йомырка сарысы, бер чәй кашыгы гәрчич һәм бераз гына тоз салып болгатырга. Әлеге катнашма майонезны алмаштыра, тәмле һәм зыянлы да түгел.

Үзем сынадым

КЫРМЫСКАНЫ ҖИҢДЕМ

Быел җәй өебезне вак кырмыскалар басып алды. Алардан котылуның бер җиңел ысулын таптым. Моның өчен нашатырь спирты кирәк. Ул кырмыскаларны үтерми, ә куркыта гына. Моның өчен 1 л суда 100 мл нашатырь спиртын болгатырга һәм кырмыска «аягы баскан» бөтен җиргә сиптереп чыгарга кирәк. 15 минуттан кешенең борыны әлеге искә иялэшә, ә кырмыскаларга бу ис бер дә ошамаганлыктан, алар чыгып китү ягын караячаклар. Әлеге ысулны берничә тапкыр кулланганнан соң, өйдә кырмыскаларның эзе дә калмады.

Зөлфия ХӘКИМОВА. Казан

Кашкарыйлар озын гомерле

Күпьеллык кашкарыйлар куак сыман булып үсәләр һәм кара көзгә кадәр, кар төшкәнче бакчаны ямьләп утыралар. Аларны ачык, кояш көшә торган, бик нык җил уйнамый торган урынга утыртырга киңәш ителә. Кышка кисеп, тамырларын каплап куйсагыз яхшы. Чәчәк ата башлагач, көз җитте дип, су сибүдән туктамагыз.

Кашкарыйларның түбәндәге сортларын сайласагыз, оттырмассыз:
- «Бичвуд Ривел» (куе кызыл);
- «Дик Баллард» (сирень төсендә);
- «Маунт Эверест» (ак);
- «Blue Danube» (зәңгәр).

УҢЫШТАН ӨЛЕШ ЧЫГАРЫР ЧАК

dumrt.ru

Шөкер, быел уңыш зарланырлык түгел, мулдан булды. Динебездә бүлешү, башкалар турында да кайгырту дигән күркәм гадәт бар. Малның бәрәкәте дә шуңа бәйле. Хәзер менә гошер сәдакасы бирер чак җитте. Аны ничек тапшырырга? Гошер бирмәү гөнаһмы? Аның сыйфатына карата таләп бармы? Әлеге һәм башка сорауларга «Билал» мәчете имамы Җәлил хәзрәт ШӘВӘЛИЕВ ачыклык кертте.

:: Гошер – нәрсә ул? Әлеге гамәл турында Коръәндә ни диелә?
– Гошер ул – бакчада үстерелгән яшелчә, җиләк-җимештән бирелә торган зәкятнең бер төре. Аллаһы Тәгалә Изге Коръәннең «Бәкара» сүрәсенең 267 нче аятендә болай ди: «И, иман китерүчеләр! Кәсеп итеп тапканнарыгызның иң яхшыларын һәм Без сезнең өчен җирдән чыгарган нәрсәләребездән сәдака итеп сарыф итегез. Үзегезгә биргән очракта күзегезне генә йомып алырдай яраксыз нәрсәләрне хәер итеп бирмәгез. Белегез: Аллаһ һичшиксез бай, мактауга лаеклы!»

:: Аның билгеле күләме бармы соң?
– Гошер-зәкятнең төгәл генә нисабы (ягъни күләме) булмаса да, елга бер мәртәбә җыелган уңышның уннан бер өлешен фәкыйрьләргә бирү фарыз санала.

:: Гошер бирмәү гөнаһмы?
– Мөмкинлегең була торып, әлеге төр сәдаканы бирмәү – гөнаһ. Аны бирүдән курыкмаска кирәк. Аллаһы Тәгалә безгә биргән сәдакабызны берничә өлеш күбрәк итеп кайтарачак. «Ибраһим» сүрәсенең 7 нче аятендә Аллаһы Тәгалә: «Мин биргән нигъмәтләргә шөкрана кылсагыз, арттырып бирермен. Әгәр биргән нигъмәтләремә шөкрана кылмасагыз, газабым каты булыр», – дип әйтә.

:: Гошерне кемгә бирергә кирәк? Мәчетләргә, картлар йортларына тапшырырга ярыймы?
– Мохтаҗларга, ятимнәргә, сәламәтлеге булмаган кешеләргә, үз-үзен тәэмин итә алмаучыларга өлеш чыгару бик саваплы. Теләге булганнар аны мәдрәсәләргә һәм башка дини уку йортларының ашханәләренә дә китерә ала.

:: Яшелчә, җиләк-җимешне генә гошер итеп кулланыргамы? Әйтик, бал, консервацияләнгән җәй нигъмәтләреннән өлеш чыгару гошердән саналамы?
– Гошер сәдакасына яшелчә һәм җиләк-җимешнең үзен генә түгел, ә алардан әзерләнгән кайнатма, салатлар рәвешендә бирү яхшырак та, чөнки алай бакча нигъмәтләре бозылмый һәм алар ны озак вакыт саклап була.

Белеп тор!

БЕЗ КИТКӘЧ ТӘ СОРАРЛАР

Кеше бу дөньядан бер китәчәк. Үлгән кешене каберગә индереп, аның янынннан озата килүчеләре таралгач, мәет Мөнкир һәм Нәкир исемле ике фәрештә белән очрашыр. Бу фәрештәләр кешедән сорау алачак.

Нинди сораулар соң бу?
1. Раббың кем?
2. Динең кайсы дин?
3. Пәйгамбәрең кем?

Иманлы бәндә исә: «Раббым – Аллаһы, динем – ислам, пәйгамбәрем – Мөхәммәд саллэллаһу галәйһи вә сәлләм», – дип җавап кайтарыр.


kzn.ru

Өч хәдис

- «Мөмкинлеге була торып, кардәшенә булышмаган кешегә Аллаһы Тәгалә дә булышмас».
- «Аллаһның ризалыгы – әти-әни ризалыгында. Аллаһның ачуы – әти-әни ачулануында».
- «Әгәр авырсагыз, авыруларыгызны сәдака биреп дәвалагыз».

Өч капчык

Гыйбрәт ал!

Бер патша өч кешегә шундый эш куша: «Һәрберегез, капчык алып, минем бакчама керегез, шунда өлгергән яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән нәрсә бар – шуны капчыкка җыегыз. Соңыннан амбар саклаучыга тапшырырсыз», – ди. Тегеләр кушканны үтәргә дип шактый зур бакчага кереп китәләр.

Берсе, өстенә йөкләнгән вазыйфасына бик җаваплы карап, капчыгын бакчада җитешкән нигъмәтләр белән тутыра; икенчесе, яртылаш кына тутырганнан соң: «Әй, ярамаган тагы!» – дип, капчыкның икенче өлешенә тиз генә чүп-чар атып, эшен тәгәлли; өченчесе исә, бөтенләй эшлисе килмичә: «Патша амбарга барып барыбер карап-тикшереп йөрмәс, нәрсәгә азапланып вакыт үткәрим?» – дип, капчыгын тулысынча таш һәм чүп-чар белән тутыра да бәйләп куя.

Бераздан бу кешеләр капчыкларын амбарга тапшыра. Кайтып китәргә дип бакчадан чыгып барганда, аларны кинәт тоткарлыйлар да:

– Патшабыз сезне бер айга зинданга ябарга әмер бирде. Шул вакыт дәвамында сез капчыкларыгызга җыйган азык белән тукланырга тиеш буласыз! – дип әйтәләр.

Патша боерганны намус белән башкарган кеше шунда: «Әлхәмдүлилләһ, ярый


Илдар Мөхәммәтҗанов

әле, тырышып, бер ай тукланырлык ризык тупладым», – дип сөенә.

Капчыгын яртылаш кына тутырганы: «Их, нигә патша кушканны җиренә җиткереп үтәмәдем икән?» – дип үкенә, ә өченчесе кайгыга төшә.

Бу дөньяда да Аллаһы Тәгалә һәркемгә савап җыяр өчен «капчык» тапшыра, кешеләр исә, нәкъ югарыда бәян ителгәнчә, өч төркемгә бүленә. Әмма нәтиҗәсе фәкать үзләренә ирешәчәк...

(Кукмара районыннан Ришат хәзрәт Курамшинның шәхси сәхифәсеннән алынды.)

Ризаэддин Фәхретдин нәсыйхәтләре

– Мәҗлесләрдә, хосусан туй вә шатлык мәҗлесләрендә булган вакытыгызда көлүдән вә гадәттән тыш уен-көлке сөйләүдән сакланыгыз. Үзегезне тота белеп вә сабыр гына, ачык йөз белән булыгыз.

– Сүз йөртүчеләр вә гайбәт сөйләүчеләрне тыңламагыз, күзегезне түбән салып тик торыгыз, үзегез белән бертигез булсалар – мондый эшләрнең яраклы түгеллеген әдәп белән аңлатыгыз, үзегездән кечкенәләр булганда, мәрхәмәт белән генә тыегыз.

– Нинди җирдә булса да, зәгыйфь вә гаҗизләр очраганда, кулыгыздан килгән ярдәмнән мәхрүм итмәгез, бигрәк тә авыр нәрсәләр күтәреп килгәннәргә юлны иркен итегез.

– Кычкырышучылар вә дәгъвалашучыларга очраган вакытыгызда араларына кермәгез, бәлки бер яктан качып китегез.

– Әдәпле кешеләрне (хәдисләр хәбәренә күрә) Аллаһы Тәгалә сөяр, халык та сөяр, исеме үзеннән соңнарга калыр, дөньяда могтәбәр вә ахирәттә дә бәхетле булыр. Һәркем моны мисал итәр, һәркем хәер-дога белән искә алыр, сагыныр.

– Халык каршында иң мәхәббәтсез кеше – мәҗлестә үз-үзен олы күрүчедер. Шуның өчен үз-үзегезне башкалардан олы санамагыз, үз дәрәҗәгезне белмичә тормагыз!

Йөгез, бер дога!

АЧУЛАНГАНДА УКЫЛА

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.
«Әллааһуммәгъфир лии зәнбии вә әзһиб гайза кальбии вә әҗирнии минәш-шәйтаанир-раҗиим».
Мәгънәсе: «Аллаһым, гөнаһларымны мәгъфирәт кыл, йөрәгемнең ачуын бетер һәм мине шайтанның явызлыгыннан сакла».


ru.pinterest.com

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук: җырчы һәм җырның исемен язып җибәрергә кирәк. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Әгәр син янына кайтмасаң, йөрәге түзмәс, өметен өзәр, ди җырчы. Ара ерак булса да, кайтырга куша ул.

Матурлыкны танып, кеше булып яшәсәң, дөньясына таң калырлык. Бу җыр әнә шул турыда.

Араларының өзелүенә еллар сәбәпче булган. Хәзер менә шуларны ялгарга чара эзли җырчы.

ГӨЛСИРИН АБДУЛЛИНА:

«КЫЗЫМ ТОРМЫШЫМНЫ БӨТЕНЛӘЙ ҮЗГӘРТТЕ»

Яңартылган федераль стандартларда балаларны финанс грамоталылыгына өйрәтү дә каралган. Россия Мәгърифәт министрлыгы белдергәнчә, сүз яңа фән кертү турында бармый. Башлангыч сыйныф укучылары математика, табигать белеме дәресләрендә гаилә бюджеты, акча тоту серләренә төшенәчәк. 5 нче сыйныфтан география, җәмгыять белеме, информатика фәннәрендә акчаны мошенниклардан саклау һәм башка темалар турында сөйләшәчәкләр.

Онлайн җыелышлар турында

Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин республика август киңәшмәсендә районнарга яңа уку елында ата-аналар өчен онлайн җыелышлар үткәрергә тәкъдим итте.

– Һәр районда мондый эш форматын оештырырга тәкъдим итәбез. Бу районнар, мәгариф идарәсе органнары җитәкчеләренә ата-аналар белән турыдан-туры аралашырга, аларга белем бирү эшен якыннанрак күзәтергә мөмкинлек бирәчәк, – диде министр.

Министрлык ел саен берничә айга бер тапкыр онлайн җыелышлар үткәрә. Анда 20 меңләп әти-әни катнаша. Интернет чарада тәрбия, психологик ярдәм күрсәтү, шулай ук иминлек һәм башка мәсьәләләр кузгатыла.

Сәрия МИФТАХОВА

Укытучы фикере

Гөлназ РӘХИМОВА, Ютазы районының Кара Зирек мәктәбе рус теле укытучысы:

– Узган уку елында мәктәп белән хушлашып, лаеклы ялга киткән идем инде. Тик кабат укытырга чакырдылар. Яшь укытучылар булмагач, кат-кат чакыралар безне. Мәктәпкә капиталь ремонт ясадылар. Бик матур, керү үк күңелле. Вай-фай да бар, барлык шартлар да тудырылган. Әмма балалар саны гына елдан-ел кими бара. Авыл җирендә эш юк. Яшьләр шәһәргә китә. Өч-дүрт авылдан мәктәпкә 70–80 укучы җыела. Минә шул проблема борчый мине.

Мәктәпләрдә әләмнәр күтәрү, гимннар башкару күптәннән кирәк иде. Бу бит – тәрбия чарасы. Кечкенә чакта әти-әниләр эшкә китә, безне йокыдан радиодан яңгыраган гимн уята иде. Мин әле дә аның сүзләрен һәм көен хәтерлим. Яшьләр үзләре яшәгән ил белән горурланып үсәргә тиеш. Илне ярат, дип әйтеп түгел, менә шундый күңелгә үтә торган гамәлләр белән аңлату файда бирә. Игелекле эшләр башкарган кешеләр турында да күбрәк сөйләү кирәк. Мәктәптә тәрбия эшенә зур игътибар бирәбез. Бер тәртипсез бала да булмады, олы тормышка аяк баскач та, берсе дә йөзгә кызыллык китермәде.

Тагын бер теләгем бар. Профильле, танылган уку йортлары белән кечкенә авыл мәктәпләрен чагыштырмасыннар иде. Зурларында көчле балаларны сайлап алырга мөмкин, кечкенәсендә әти-әниләргә каршы килеп булмый. Мин монда имтихан нәтиҗәләрен күздә тотам. Чабышкы белән эш атын бер вакытта да ярышка бергә чыгармыйлар. Һәрберсе аерым чаба. БДИны пандемия чорындагы кебек вузга керүче балалар гына бирсен иде, көллияткә баручыларга сайлау мөмкинлеге кирәк. Ул аларның психикасын бик боза. Мәктәптә бөтен әйбер дә ярышка әйләнмәсен иде.

ГАИЛӘ БЕР – БАЙЛЫК ТӨРЛЕ

НИКАХ КИЛЕШҮЕ НЕЧКӘЛЕКЛӘРЕ

«ВТ» архивыннан

Өйләнешкәнче килешәсе. Уртак оя корып яшәр алдыннан, парлар арасында никах килешүе (брачный договор) төзү күренеше ешрак очрый башлады. Дөрес, Европа илләрендә, АКШта ул гадәткә күптән кергән, гаҗәп тә түгел инде. Әмма Россиядә бу эшкә шикләнебрәк карыйлар. Тумаган тайның билен сындыру булмасын дипме, өйләнешмәгән килеш аерылышу турында уйлауны саранлану, байлык бүлешү кебек кабул итәләр. Асылда килешү нигезендә нәрсә ята соң?

Никах килешүенең дә, медальнең ике ягы булган кебек, бик файдалы һәм файдалы ук булмаган яклары бар. Тормыш булгач, хәлләрнең дә төрлесенә юлыгасың. Бик матур, үрнәк пар булып, шундый гаилә корган кешеләрнең дә көннәрдән бер көнне нигезе какшап китәргә мөмкин. Ул чакта мал-мөлкәт, акча, фатир, балалар мәсьәләсе араларны тагын да салкынайтмагае. Кыен хәлдә калмас, вакыт һәм нерв күзәнәкләрен дә саклар өчен, булачак ир белән хатын килешү төзеп өйләнешә дә инде.

Димәк, әлеге адымны ясаганчы ике кешегә психологик яктан да, юридик яктан да әзер булырга кирәк. Хокукый үзенчәлекләрен аңлатыйк.

Нәрсәдән гыйбарәт?

Никах килешүе ул – ир белән хатын яки булачак ир белән хатын арасында никахка кадәр тупланган мал-мөлкәтнең һәм гаилә коргач табылганының киләчәктә ничек бүленәчәген күздә тотып төзелгән килешү. Гади итеп әйтсәк, бу – бергә яшәгәндә яисә аерылышканда гаилә-милек мөнәсәбәтләрен «иминиятләштерү», акчаны һәм мөлкәтне яклау.

Уңай яклары

Никах килешүе ир белән хатынның хокук һәм бурычларын төгәлләштерергә мөмкинлек бирә. Бу инде алга таба мал-мөлкәт бүлгәндә бәхәс-гаугалар килеп чыгудан да саклый. Бурыч, кредит, бүләкләр мәсьәләләренә бәйле сорауларга да никах килешүендә җавап табарга була.

Килешүне гаилә корганчы да, никахлашканнан соң да төзергә ярый.

Никах килешүеннән бер генә як баш тарта алмый. Килешүгә икәү килгән кебек, бу очракта да бергә хәл итү шарт.

Тискәре яклары

Билгеле, төгәл, аңлаешлы һәм дөрес килешүне хокукый яктан белеме булмаган кеше белән төзү кыен булыр иде. Димәк, парларга нотариаль һәм юридик хезмәтләрдән файдаланырга туры киләчәк. Бу исә – өстәмә чыгым. Сүз уңаеннан, хезмәт күрсәтүчеләрнең бәяләре дә төрле. Килешүне рәсмиләштерү хакы 5 меңнән алып 50–100 мең сумга кадәр җитә ала. Барысы да эшнең катлаулылыгына бәйле. Моннан тыш никах килешүе өчен 500 сум дәүләт пошлинасы түләү каралган.

Никах килешүе парлар рәсми төстә гаилә булып теркәлгәннән соң гына гамәлгә керә.

Шунысы да бар: җәмгыятьтә законнар да үзгәрүчән бит. Теге яисә бу канун үзгәрешләре никах килешүендә күрсәтелгән шартларга да тәэсир итәргә мөмкин.

Тагын бер мәсьәлә әхлакый якка бәйле. Никах килешүенә кешеләр күбесенчә тискәре караштa. Кеше ни әйтер дипме, күпләр мондый килешү белән яшәүләрен яшерә.

САН

Федераль нотариаль палата мәгълүматларына күз салсаң, 2020 елда Россиядә 142,5 мең никах килешүе төзелгән. 2021 елда – 148,3 мең. Белгечләр әлеге күренешнең популярлаша баруын искәртә.

Россиядә аерылышулар саны 2022 елның беренче дүрт аенда 1 процентка кимегән. Тулаем алганда, Идел буе федераль округында аерылышулар саны 3,1 процентка азайган.



ТӨГӘЛЛЕК МӨҺИМ

*Гражданнар эшләре буенча юрист **Ләйсән МОРТАЗИНА**дан никах килешүенең өстенлекләренә, килешү төзегәндә игътибарга алырга кирәк булган мәсьәләләргә ачыклык кертүен сорадык.*

– Ләйсән Маратовна, никах килешүе гаилә тормышын җиңеләйтүдә нинди роль уйный?

– Никах килешүен төзү өчен бик күп сәбәпләр бар. Әмма, юрист буларак, һәр ситуацияне аерым карарга кирәк дип саныйм. Шул вакытта гына кайчан килешү кирәк, кайчан юк икәне аңлашыла. Мисаллар белән карыйк.

Беренче сәбәп – никахлашуга кадәр булдырылган бизнес. Мансур – уңышлы гына үз эшен алып баручы эшмәкәр, хатыны Лилия – студент. Мансур үз бизнесын Лилия белән очрашып йөри башлаганчы ук ачса да, керемне инде гаилә коргач кына ала башлый. Уртак мөлкәтләре юк. Киләчәктә фатир һәм машина сатып алырга ниятлиләр. Сатып алынасы милек уртак булачак. Монда инде бу эшкә кайсының күпме өлеш кертүе исәпкә алынмый.

Никах килешүе нигезендә исә Мансурга – фатир, Лилиягә машина эләгәчәк дип килешергә була. Аннан соң булдырылган мал-мөлкәт уртак саналачак. Бу гадел дә. Чөнки Лилия дә, укуын тәмамлап, эшкә урнашачак.

Икенче сәбәп – яңа төзелә торган йорттан фатир сатып алу. Алмаз өч бүлмәле фатир төзелешенә акча керткән. Ачкыч һәм белешмәне ул ике елдан соң гына кулына алачак. Ә ул инде сөйгәне Алсуга тагын бер елдан соң өйләнергә җыена. Кагыйдә буларак, фатир уртак мал саналачак. Аерылышкан очракта, суд бу фатирны ике кеше арасында бүлмәсен өчен, Алмазга әлеге фатирны шәхси акчасына сатып алганын исбатларга кирәк. Нишләргәме? Алмаз һәм Алсу никах килешүе төзи. Анда фатирның Алмазныкы булуы күрсәтелә.

Өченче сәбәп – туйга бүләк. Наил белән Альбинага әти-әниләре Казаннан фатир бүләк итә. Бу бүләк өчен алты миллион сумны – кәләш ягы, өч миллионны кияү ягы салган. Милек турында белешмәне яшь гаилә туйдан соң ала. Кагыйдә буларак, гаилә таркалса, бу фатирны икегә тигез итеп бүләргә тиешләр.

Никах килешүе нигезендә, Наил белән Альбина менә нишли: йортның 2/3 өлеше – Альбинага, 1/3 өлеше Наилгә дип килешә.

Дүртенче сәбәп – аерым бюджет. Альберт белән Алинә – яхшы карьера булдырган кешеләр. Күп акча эшлиләр, әмма аерым бюджет тоталар. Альберт үзенә машина сатып ала, Алинә исә шәһәр читендәге йорт хуҗасы булып куя. Закон нигезендә, Алинәгә иренең джибыннан, ә иргә хатынының йортыннан 1/2 өлеш тиеш.

Никах килешүе бәхәскә нокта куя. Гаилә әгъзалары үзләре сатып алган милекнең бердәнбер хуҗалары булуын күрсәтә. Һәркем үзенеке өчен үзе җавап тота.

– Ипотекасы, кредиты булган парларга нишләргә?

– Аерылышканда, гаиләнең гомуми мөлкәтен ничек бүләсе аңлашыла. Ипотека фатирын һәм кредит бурычын бүлешергә туры киләчәк вазгыять шактый сораулар тудырырга мөмкин. Бу очракта кредитка сатып алыначак күчемсез милеккә никах килешүе (брачный договор на недвижимое имущество) төзү кулайрак булыр.

Ипотека очрагында, никах килешүе кайчан кирәк? Бу банкның шарты да булырга мөмкин. Шул рәвешле кредитор үз мәнфәгатьләрен дә яклый. Әйтик, гаилә таркалса, ир яисә хатын, кереме кимү сәбәпле, заемны түли алмаска мөмкин бит. Никах килешүе булганда, банкка бу мәсьәләне чишү күпкә җайлырак.

Шулай итеп, нинди очракта никах килешүен төзү отышлырак? Бердән, әгәр дә гаиләдә бер генә кеше керем алса. Ягъни берсе генә эшли, берсе генә ипотека түли. Икенчедән, никах килешүе ипотека рәсмиләштергәндә дә отышлы. Ир яисә хатын, заемщик буларак, ипотека алу өчен тиешле дәрәҗәдә керемгә ия булмаска да мөмкин. Ә никах килешүе аларның кредитны түли алачагына гарантия бирә. Өченчедән, ир яисә хатын ипотека алырга теләмәгәндә, никах килешүе ярдәмгә килә. Закон буенча, ипотека кредитын рәсмиләштерү өчен заемщикның тормыш иптәше булган кешенең рөхсәте сорала. Никах килешүе бар икән, кредитны ансыз гына да бирәләр. Дүртенчедән, ир белән хатын ипотеканы рәсми төстә гаилә булып яши башлаганчы алса. Аерылышканда, никахлашканчы сатып алынган мал-мөлкәт үзара бүленми. Никах килешүе фатирны йә йортны гадел рәвештә бүләргә ярдәм итәчәк.

Никах килешүендә милек сораулары гына көйләнә. Көнкүреш, шәхси тормыш, балаларга бәйле аңлашылмаучанлыклар анда күрсәтелми. Әйтик, килешүгә ирегез яисә хатыныгызның гомер иткәндә артык авырлык җыюы, вәгъдәсендә тормавы, хәмер эчүе, хыянәт итүенә бәйле штраф салу кебек шарт кертү – мәгънәсез гамәл.

Эчтәлеге нинди?

«Арбитр» юридик үзәге никах килешүенең эчтәлегенә ниләр керергә тиешлеген һәм нинди очракта килешүне гамәлдән чыгарырга мөмкин булуын аңлатты.

– Килешүдә мал-мөлкәтне бергәләп куллану, тоту буенча хокук һәм бурычлар билгеләнә. Шулай ук бу документта ир белән хатынның керемдә катнашы, гаилә чыгымнарын тоту ысуллары, мөнәсәбәтләр өзелгән очракта ир белән хатынның һәркайсына тапшырылачак мөлкәт күләме, милек мөнәсәбәтләренә кагылышлы теләсә нинди башка нигезләмәләр, хокук һәм бурычларны чикли торган шартлар күрсәтелә, – дип аңлата үзәк белгечләре.

Никах килешүен ике якның ризалыгы белән теләсә кайсы вакытта туктатырга мөмкин. «Моннан тыш ир яисә хатынның таләбе буенча, суд карары нигезендә, әгәр икенче як килешү шартларын шактый бозса яисә яклар аны төзегән вакыттагы сәбәпләр үзгәрсә, гаилә рәсми рәвештә таркалса, никах килешүен өзәргә була», – дип аңлата белгечләр.

Кайсы очракта дөрес түгел?

Никах килешүен гамәлдә түгел дип тану очраклары: суд карары; килешүнең ир белән хатынның хокукый сәләтен яки эшкә сәләтлелеген чикләве; балаларына карата хокук һәм бурычларны чикләве; нотариус расламаган; килешүнең эшкә яраксыз зат тарафыннан имзалануы; шарт буларак милек булмаган мөнәсәбәтләр, шәхси мөнәсәбәтләр күрсәтелү.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

БИРЕШМӘГЕЗ!

Күпләр хәтерлидер: «Ватаным Татарстан» газетасы 2017 елда, Диана Долгаевага багышлап, хәйрия концерты уздырган иде. Без ул чакта Казахстан кызына ярдәм итәргә алындык. Дианаҗның әнисе, ярдәм итүебезне сорап, үзе элемтәгә чыккан иде.

Диана 2015 елда авырый башлый. Әнисе 10 яшьлек кызының хәле китүенә игътибар итә. Ул гел утырып тора, температурасы күтәрелеп җәфалана.

– Күңелем сизгәндер инде: балама карадым да, синең каның яхшы түгелдер, дидем. Бу сүзләрне әле дә хәтерлим. Тиз арада кан анализы тапшырдык. Нәтиҗәләрен белергә килгәч, табибларның йөгерешеп йөрүеннән безнең хәлнең начар икәнен аңладым. Сизенүем дөрес булды. Кызыма лейкоз диагнозы куйдылар, – дип сөйли Ольга. – Диананы озак дәваладык. Әмма табиблар ничек кенә тырышса да, чир чигенмәде. Җитмәсә, балада башка авырулар да барлыгы ачыкланды. Канына инфекция эләкте. Башка клиникага мөрәҗәгать итәргә булдык. Ә анда бик зур суммада акча сорадылар. Безгә Россия волонтерлары булышты, Татарстан халкы акча күчерә башлады. Хәйрия чаралары уздырдык.

Арка мие күзәнәкләрен күчереп утырту өчен Дианага шактый дәваланырга туры килә. Башта анализлары яхшырып киткәнне көтәләр. Аннары инде яхшы күңелле кеше табылып, кызга донор була. Әмма чит күзәнәкләр тиз генә эшләп китми. Дианаҗның эчәкләрендә дә бер-бер артлы авырулар барлыкка килә. Өмет кими. Тик Дианаҗның яшәү көче җиңеп чыга. Ул әкренләп аякка баса. Әнисе, Диананы бәллүр савыт кебек кадерләп кенә саклап яшәдек, ди.

– Моннан 2,5 ел элек табиблар кызымда яман чир күзәнәкләренең беткәнен, аның сау-сәламәт икәнен әйттеләр. Арка мие күчереп утыртканга 5 ел тулды. Күптән түгел шуны бәйрәм иттек. Аллага шөкер, баламны коткардыгыз. Татарстан халкына ничек рәхмәт әйтсәм дә, җитәрлек булмас кебек, – ди әнисе. – Диана гел «бишле»гә генә укыса да, авыруы аркасында дәресләргә йөри алмады. Хәзер ул укуын онлайн мәктәптә дәвам итә. Иң мөһиме – сәламәтлек. 16 яшьлек кызым моны үзе дә яхшы аңлый, күп нәрсәгә карашы үзгәрде. Бик игелекле булып үсеп килә. Киләчәктә үземне аякка бастырган табиб кебек буласым килә, дип хыялллана. Үзен медицина белән бәйләмәкче. Без моңа шат кына.

Бу вакыйга аларның бөтен тормышын үзгәрткән. Ольга яман чир белән авыручы кешеләргә кулдан килгәнчә булышырга тырыша. Аларга төрле киңәшләрен бирә. Кайсы клиникада ничек дәвалауларын әйтә. Кайчак акча җыярга да ярдәм итә икән.

– Зур очрашуга әзерләнәбез. Кызыма үзенең арка мие күзәнәкләрен биргән кеше белән күрешәчәкбез, – ди ул. – Дианаҗның савыгуы – яман чирне дә җиңеп булуга бер мисал. Нинди генә авыру килсә дә, бирешмәгез! Ничек тә яшәргә, дәваланырга тырышыгыз. Теләк булса, чир дә көчсез. Кызым да, без дә шуны аңладык!

АВЫРУ БАЛА ӘНИСЕ:

«УЛЫМ, ТОР ӘЛЕ, ДИСӘМ...»

vk.com

Олы Кайбычта яшәүче Гарәфетдиновлар гаиләсе әле дә могҗизага ышана. Алар улларының хәле яхшыруына өмет итә. 16 яшьлек Илназның бер кочак диагнозы булса да, моңа кадәр ул әле үзе сулый да алган, тамагына да ашаган. Әти-әнисе шуңа да риза.

– Улым вакытыннан алда дөньяга аваз салды. Өч көннән хәле начараеп китте. Бөтен тәне саргайды, аны көзән җыера башлады. Шуннан соң безне Республика клиник балалар хастаханәсенә алып киттеләр. Ул чакта баламда нинди дер авыру бардыр дип уема да килмәде. Табиблар да берни әйтмәде. Бары тик бер яше тулгач кына аның яшьтәшләреннән аерылып торганын чамалап алдык. Шуннан соң табибларга йөртә башладык. Тикшерә торгач, ДЦП диагнозы куйдылар, – дип сөйли әнисе Алия.

Табиблар ышерми: Илназның үзе йөри алмасын, ятып кына торачагын әйтәләр. Хәтта Алиягә сабыен хастаханәдә калдырып чыгарга киңәш итүче дә табыла. Әмма ул үз нарасыеннан баш тартмый. Ничек итсә итә, әмма үзендә көч табып, баласын ташламаячагын әйтә.

– Нинди булса да, безнең көтеп алынган балабыз бит ул. Аны ташлап, нинди күңел белән яши алыр идем икән? Мин бу хакта хәтта уйларга да куркам. Илназыбыз бик кадерле безгә. Бар тормышым аның янәшәсендә узса да, бер дә читенсенмим. Миңа ярдәм итүче ирем, якыннарым бар, – ди Алия.

Илназ ятып кына тора. Әти-әнисе аны кашыктан ашата, юындыра, йоклата. Гарәфетдиновлар көн саен бер рәвешле яшәүгә күнегеп тә бетә. Тик 2020 елның сентябрендә Илназ комага китеп, аның хәле тагын да катлаулана.

– Улым төнлә начар йоклагач, иртән соң тора иде. Комага киткән көнне мин аны әле дә йоклыйдыр дип уйладым. Бүлмәсенә кердем дә, улым, тор инде, дисәм, ул күзләрен ачмый. Нишләтергә белмәдем. Кулыма күтәреп алып, бер бүлмәдән икенчесенә тик йөгереп йөрим. Бераздан хәленең начар икәнен аңлап, «ашыгыч ярдәм» чакырттым. Ул чакта улымның кандагы шикәр күләме икегә төшеп беткән булган. Шушы хәлләрдән соң Илназ үзе сулый да, какырыгын чыгара да алмый башлады, – ди Алия.

Табиблар сабыйны ИВЛ аппаратына тоташтыралар. Ашказанына һәм бугазында тишек калдырып, махсус аппарат куялар. Илназ шушы җайланмалар белән яши башлый. Элеккеге кебек кашыктан ашатулар бетә. Әнисен дә танымаска әйләнә.

– Балам авыргач, мин өйдә генә торам. Тормышны алып бару ирем өстендә. Ә Илназга кирәкле җайланмалар да, аны ашатыр өчен махсус ризыклар да кыйммәт тора. Табиблар хәзер бары тик аксымлы ризык кына ашатырга кушты, – ди Алия. – Шуңа да чит кешеләрдән ярдәм сорарга булдык. Улыма аена 30 банка ризык алырга кирәк. Аның берсе 1300 сум тора. Димәк, аена 39 мең сум кирәк дигән сүз. Без бу акчаны берничек тә үзебез генә җыя алмыйбыз. Ярдәм итсәгез иде.

Гарәфетдиновларга булышырга теләүчеләр өчен Алия Рузалит кызының Саклык банкы картасы номеры: 2200530141640821. Әлеге карта 89274208346 телефон номерына беркетелгән.

Туй урынына ашын уздыралар

Питрәч районының Чыты авылы халкы әнә шулай ди. Моннан бер атна элек авылдашлары Ләйсән Абдуллинаның үлеме һәркемне тетрәндерә. Сабый чактан ятим калган кыз, үз әнисеннән бары тик 2 ел гына артык яшәп, 32 яшендә юл фаҗигасендә һәлак була.

– Күңелгә бик читен. Без күрше генә яшибез. Һәрвакыт аралашып тордык. Ләйсән Казанда эшләде. Әмма җәй айларында гел авылда иде. Каз бәбкәләре сакларга кирәк булса да, печән әзерләр вакыт җитсә дә, кайтып җитәр иде. Әти-әнисенә бик ярдәм итте ул. Соңгы вакытта күршеләребез мал санын арттырдылар. Иртән Казанга барып, сөт, каймак саталар иде. Ләйсән исә иртән малларны көтүгә чыгара иде. Фаҗига буласы көнне ул бөтен күршеләрнең сыерларын үзе куып алып киткән, – дип искә ала күршесе Миннур Шәмсетдинов. – Ләйсән авылдан Казанга барганда машинасы белән дамба астына төшеп китә. Гомере шунда өзелә.

Әниләре яман чирдән вафат булгач, берсеннән-берсе кечкенә өч бала ятим кала. Әтиләре Миңнулла абый үзенә хатын итеп ике баласы белән Сабада яшәүче Рәүфә апаны алып кайта.

– Ләйсән дә, энеләре дә Рәүфә апаны үз әниләре кебек якын күрде. Ул да ятим сабыйларга ана җылысын биреп үстерде. Ләйсәнне югалтуны бик авыр кичерә. Безгә дә бик авыр. Ничек болай булды соң дибез? Язмышына шулай язылгандыр. Матур итеп туйлар уздырасы урынга әниләре ашын үткәрә. Күрәчәктер инде, – ди Миннур. – Ләйсәннең Казанга китеп баруын күрдем мин. Икебез дә бер вакытта өйләребездән чыгып машинага утырдык. Күтәрелеп карамасмы дип көткән идем. Ул мине күрмәде. Үзем дә юлдагы кешене бүлдермәскә уйлап, дәшми калдым. Мин аска, ул өскә таба кузгалып киттек. Үлем исереклеге белән йөрде микән? Юкса әллә каян кул болгап, сәлам бирә иде. Авылыбыз зиратына әнисе янәшәсенә җирләдек. Рухы шат, урыны оҗмахта булса иде.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ГӨЛҖАМАЛ

Артистны тамашачы бер роле белән истә калдыра. Шул роле белән башкаларын чагыштыра, сыный, бәя бирә. Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Люция ХӘМИТОВА, мөгаен, күпләр өчен Гөлҗамалдыр. Бу рольдә аның бөтен барлыгы, эчке дөньясы ачыла кебек. Без рольләр, театрның шәхескә һәм гаиләгә тәэсире, үзенчәлекле чорлар турында сөйләштек.



Люция Хәмитованың шәхси архивыннан

:: Сез театрга ашкынып килеп керәсез, йөрешегез кызу, җиңел, бию кебек. Мөгаен, бала чакта бию түгәрәгенә йөргәнсездер...

– Мин аны үзем дә белми идем, ашкынып йөрисез, диләр шул. Ул – халәтемдер... Бию дигәннән, кечкенәдән мәктәпне тәмамлаганчы бию түгәрәгенә йөрдем. Шуңа бөтен төзелешем, атлап йөрүләрем биючеләрнеке кебек. Фәрит (Бикчәнтәев – Камал театры баш режиссеры, хәләл җефете. – **Ред.**) тә иң беренче шуңа игътибар иткән бит. «Карыйм, бер кыз бара, аяклары беренче позициядә», – дип сөйләгән иде. Билгеле, хәзер инде хореографиянең кайбер нечкәлекләре онытылган.

:: Ә театр белән җенләнү кайчан башланды?

– Кечкенә чакта, кем буласың, дип сорасалар, артистка булам, дип җавап бирә идем. Мөгаен, бу гаиләдән киләдер. Әти-әнием театр җанлы кешеләр иде. Без премьераларны калдырмыйча театрга йөрдек. Спектакльне исә сәхнәгә кереп китеп, дөньяны онытып карый идем. Мин барлык спектакльләрне, артистларны белә идем. Мин мәктәп баласы булган елларда Фәрит Камал театрында эшли башлады. Яшь, талантлы артист бик тиз минем кумирыма әйләнде. Бөтен кызлар кебек, мин дә аңа гашыйк булдым. Язмыш дими, ни дисең: миңа Камал театрында эшләү, Фәрит белән гаилә кору насыйп булган. «Сез рус мәктәбендә укыгансыз, ничек татар театрын сайладыгыз?» – дип сораучылар да бар. Мин бит татар мохитендә үстем. Әтием – авыл баласы, әниемнең дә әти-әнисе авылдан булгач, безнең өйдә татарча сөйләштеләр. Бәлкем бу гына җитмәгән дә булыр иде, мине каникулда дәү әни белән бабай янына кайтарып куялар иде. Шуңа күрә минем театр училищесында татар бүлеген сайлавым да табигый булды. Гәрчә, рус бүлеге зуррак мөмкинлекләр ача, дип киңәш бирергә омтылучылар булса да. Татар бүлегендә укыганда төп хыялым Камал театрына эләгү иде. Ләкин анда эшләү бөтен кешегә дә тәтеми. Мине дә башта ярдәмче составка гына алдылар.

:: Сүз уңаеннан, сезгә «Гөлҗамал»дагы кебек биюле рольләр бик килешә. Үзегез иң кадерлеләре дип кайсы рольләрегезне атар идегез?

– Биюле рольләр яшь чакта шактый иде. Әйтик, «Биюче»дә (Лопе де Вега) Фелисьяна гел биюле роль иде. Хәзер «Бию пәрие»ндә әби ролендә биим (*көлә*. – **Ред.**).

Ә «Гөлҗамал»га килгәндә, шәхесне уйнау ул – зур җаваплылык. Ләкин без шәхесне гәүдәләндерүдән бигрәк, алар башкарган эшне күрсәтүне максат итеп куйдык. Аларның театр оештырабыз дип янып-көеп йөрүләре, шул юлдагы табуюгалтулары, шушы максатка җаннарын фида кылулары... Театр җиңел төзелмәгән, ул бик күп көч, хәтта гомерләр бәрабәренә барлыкка килгән, безгә ул шуңа да бик кадерле, дигән фикерне җиткерә алдык дип уйлыйм. Гөлҗамал (Сәхипҗамал Волжская) – бик кадерле һәм иҗатымның бер этабын гәүдәләндергән роль. Шөкер, андый кадерле рольләр шактый булды. Болар – «Кара чикмән»дәге (Георгий Хугаев) – Чибәр, «Җирән чичән һәм Карачәч сылу»да (Нәкый Исәнбәт) – Карачәч, «Өч сеңел»дә (Антон Чехов) – Маша, «Санаулы кичләр»дә – Тамара, «Килмешәк»тә (Сөмбел Гаффарова) – Жоанна, «Мөһаҗирләр»дә (Мәхмүт Галәү) – Патый һәм Норвегия драматургы Юн Фоссеның «Җәйнең бер көнендә» спектаклендәге Хатын персонажы... Ул – бик авыр һәм кадерле рольләрнең берсе. Бу спектакльдә эшләү алымы да башкача булды. Сөйләм үзгә, чөнки спектакль буеннан буена ритмик прозага нигезләнгән. Аннан соң без аны Кече залда уйнадык. Ә минем героиня ул бертуктаусыз тамашачы белән аралаша. Ул аларның күзләренә карап сөйли һәм хатирәләрен искә төшерә. Тамашачының кул сузымында гына булу авыррак иде. Беренчедән, сиңа беренче тапкыр күргән кешегә (тамашачыга) үзеңнең эчке дөньяңны ачып салырга кирәк. Ә без зур сәхнәдә үз партнерларыбыз белән эшләргә күнеккән. Икенчедән, бу кешеләр белән аралашканда чикләрне югалтырга ярамый. Хисләргә дә артык бирелергә ярамый, тамашачының хисләрендә дә артык уйнарга ярамый. Һәр ике очракта да ихласлык югала. Без бит зур сәхнәдә күренсен, ишетелсен дип күпертебрәк уйныйбыз, монда бөтенләй икенче мохит. Шунысы белән кызык иде дә ул. Менә бу мәктәпне үткәч, «Килмешәк»тә Жоанна ролендә (бу образда Люция Хәмитова сәхнәдә шул мизгелдә карчыкны, шул ук мизгелдә аның яшь чагын уйный. – **Ред.**) җиңелрәк булды. Дөрес, һәрбер рольнең үз авырлыгы бар. Менә хәзер «Мөһаҗирләр»дә Патый карчык роле дә минем өчен бик кызык.

:: Сезнең рольсез утырган чак булмагандыр да. Режиссер хатыны булгач, ул рольсез утырмый инде, дип башка актерлар үпкәләрен белдермиләрме?

– Әйе, аны гомер буе әйттеләр. Нишлисең инде, режиссер хатыны булгач... Ул табигыйдер инде, аны ничек бар, шулай кабул итәргә кирәктер. Гәрчә иң уйный торган чакта биш ел рольсез дә утырдым. Иң кызыгы: ул чакта да, Люция күп уйный инде ул, дип әйтәләр иде.

:: Өйдә эш турында сөйләшәсезме?

– Сөйләшәбез инде, кая китәсең? Барыбыз да бер юнәлештә, бер эштә булгач, ияреп кайта инде ул.

:: Мөгаен, яшь вакытта танылган актриса килене булу җиңел булмагандыр. Каенанагыз нинди холыклы кеше?

– Ничектер барысы да бик табигый барды. Әни буларак исә ул (Наилә Гәрәева – Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты. – **Ред.**) – бик борчылучан, кайгыртучан кеше. Хәтта кирәгеннән артык борчылучан, чамадан тыш кайгыртучан дисәк тә була. Хәер, мин үзем дә шундый. Гел борчылам, булмаган әйбергә дә кайгыра башлыйм. Килен каенана туфрагыннан ярала, диюләре хактыр. Мин аңа бик рәхмәтле. Йосыфны музыка мәктәбенә йөртүне дә бит ул тулаем үз өстенә алды, тәмамлаттырды, аның белән шөгыльләнде.

:: Йосыф – шәп музыкант, өстәвенә спектакльләргә музыка да яза. Әти-әнисенә ул нинди бала, холкы нинди?

– Йосыф ГИТИСта ике ел режиссура бүлегендә укыды һәм, бу минеке түгел, дип әйтте. Ул – җаны-тәне белән музыкага бирелгән кеше. Кариев театрында «Йосыф» спектакленә музыка язды. Ул – аның беренче эше. Бу юнәлештә барыбер спектакльне тою, аңлау өчен аңа ГИТИСта алган белеме ярдәм итә. Аннан соң ул бит үзе дә кечкенәдән спектакльләрдә катнашып үсте, сәхнә кагыйдәләрен, үзенчәлекләрен эчтән белә.

> Алар – үзенчәлекле, безгә бөтенләй охшамаган буын. Максатчаннар, эзләнүчәннәр, ниндидер нәтиҗәләргә ирешү белән мәшгульләр. Аннан килеп, алар бит бөтенләй башка мохиттә, башка шартларда үстеләр. Йосыф балалар бакчасына киткәндә русча белми иде дә. Ана сөте белән кергән тел ул онытылмый инде. Гомумән алганда, ул – Наилә һәм Сания әбиләренең тәрбия җимеше.

Холкы буенча Йосыф – минем әткәй. Мин аның үзенә дә, син – икенче Миннеәхмәт, дип әйтәм. Чөнки әти кебек үк кешеләргә ачык, якты, әмма безнең белән ябыграк. Шул ук вакытта безнең фикергә колак сала. Аннан соң Йосыф – гипертыйнак кеше. Мин аңа, бераз әрсезрәк бул, тормышта җиңелрәк булыр, дим. Әйтеп кенә холыкны үзгәртеп буламыни? Әти җиде ел элек бакыйлыкка күчте. Төсе Йосыфта калды.

:: Бер бала белән генә калганга үкенмисезме?

– Иң зур үкенечем ул. Әмма туксанынчы елларда бик күпләр бер бала белән калган икән. Ник дигәндә, дөньяның кая барганын, иртәгә нәрсә буласын аңлап булмый торган дәвер, юклык заманы иде. Аннары дөнья да җайланды кебек, икенче бала артыннан барырга соң иде инде.

:: Хәзер дә бик үзенчәлекле чорда яшибез бит. Кыйммәтләр алмашына, тормышка карашлар үзгәрә. Үлем-җитемнәр дә күбрәк кебек. Менә мондый шартларда тамашачыгызга нинди киңәшләр бирер идегез?

– Үлем-җитем ул кайсы заманда да булган. Ковид булмаса, онкология чире, бүтәннәр бар иде. Башка заманнарда без статистиканы бик белмәгәнбездер, хәзер исә, ковид популяр чиргә әверелгәч, көн саен яңа саннар белән танышабыз. Шуңа да үлем-җитем күп кебек тоела. Ә заман... ул һәрчак үзенчәлекле. Сугыш еллары, ачлык еллары... Менә безнең хәзер «Мөһаҗирләр» спектакленең икенче өлеше репетициясе бара. Кирәк бит, ә, бөтен нәрсә әйтелгән, тарих спираль буенча әйләнә, дип шаккатабыз. «Мөһаҗирләр» – театр өчен бик әһәмиятле спектакль. Анда һәр кеше үзенә кирәкле сүзне, киңәшне табачак.

...Һәр заман үзенчәлекле. Һәр заманда, нинди генә авырлыклар килсә дә, карашлар театрга төбәлә. Чөнки театр өмет бирә, рухи азык белән тукландыра, үзүзеңә ышанычны ныгыта. Театр коллективы шуны аңлап эш итә, ул барыбер үз сүзен әйтә, үз вазыйфасын үти.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА



Булат ИБРАҺИМ

***

«Син безгә нигә, әйт әле», –
Диючеләргә җавап
Әйт шуларга, туган телем,
Сорамасыннар кабат.
Әйт шуларга, тыйнакланма,
Тыелып беттең инде.
Кеше көен көйли-көйли,
Көелеп беттең инде.
Әйт, телем, шартлатып сөйлә,
Йоклаганнар сискәнсен.
Алай иртә күммәсеннәр,
Гайрәтең бар, исән син.
Син сәүдәләр йөрткән тел бит,
Тарих, ярлыклар язган.
Телеңнән ваз кичүчегә
Надан дигән сүз таман.
Син догалар кылучы тел –
Аллаһны зурлаган тел.
Син, яуларда җиңү яулап,
Тынычлык сораган тел.
Башларын чайкап утырсын
Телсезләр, томаналар.
Телләрен җуйган халыклар
Берзаман югалалар.

Берзаман югалалар шул,
Ә югалгач, табылмас.
Менә инде ул чакларда
Тешләргә тел дә булмас.
Шул тел белән үз ипиен
Табып баеп беткәчтен.
«Нигә миңа бу тел?» – диеп,
Оран салып йөргәчтен.
Ана телен ят иткәннәр
Ят итмәсме анасын?
Мин шикләнәм, бик шикләнәм,
Раббым үзе сакласын.
«Син безгә нигә, әйт әле», –
Диючеләргә җавап.
Телең булганда телеңне
Кадерлә, кардәш, ярат.

***

Ил зур безнең,
Шуңа күрә микән
Һәркем өчен газиз ватаны.
Һәр кешенең үз кояшы монда,
Үз яңгыры монда, үз таңы.
Ил зур безнең:
Саклыйм дисәң әгәр,
Саклап бетергесез җире бар.
Санап бетергесез дошманнары,
Табиблары җитмәс чире бар!
Ил зур безнең,
Ә эчендә аның
Яклаучысы яши бик күпләр,
Саклаучысы калган
хатыннар бар,
Яклаучысы калган бар ирләр.
Ил зур безнең:
Кайда аның чиге,
Кайда Ватан бетә, кайда ил?
Батырларның каберенә туктап,
Тыныч кына дога кыла җил.

***

Йа Раббым,
Бу ничәнче гасыр?
Бу ничәнче буын алышына?
Әле кичә генә туган сабый
Тормыш дигән олуг ярышына
Мүкәләргә әзер.
Әле кичә генә туган сабый
Сафлык дигән самимилек
белән,
«Әннә», – диеп телен
ачкан иде,
Күзен ачып, дөнья ачкан иде.
Бу ничәнче буын алышына?
Заман тавышына,
Бу ничәнче буын,
Азан агышына колын селтәп
Кайный бирә үзенең
сагышында?
Әле кичә генә туган сабый,
Төнге айны азгын икән, диеп,
Йолдызларны монафыйк,
дип үртәп,
Күктән эзли гаеп.
Йа Раббым,
Син Җир шарын зур
намазлык иттең.
Әле кичә генә туган сабый
Синнән ярдәм сорый,
сәҗдә төшә,
Тик кыйбласы берәү
түгел аның,
Әллә ничә...
Йа Раббым,
Бу ничәнче гасыр?
Бу ничәнче буын алышына?..

***

Бу заман шулкадәр тизләнде,
Үзгәрде яшәүнең мәгънәсе.
Әйдәле шушында тукталыйк,
Тукталыйк һәм бераз
көч алыйк.
Каядыр ашыгу, ашкыну,
Нигә соң? Кайда соң? Белгән юк,
Беләсең без инде күптәннән,
Ихластан шатланып көлгән юк.
Югыйсә дөньясы бер көлке,
Көлеп ят мәгънәсез сүзләрдән.
Көрешәбез кебек үзебез,
Сөйләшкән генә юк күптәннән.
Югыйсә сөйләшер әйберләр
Бихисап бу салкын шәһәрдә.
Тик нигә?
Нигә соң әле дә
«Иртәгә, әйдәле, иртәгә».
Әйдәле, барысын ташлыйк та
Сикерик туктамас арбадан.
Нилеккә бу синең шөһрәтең?
Нилеккә бу сиңа ялган дан?
Нигә бу якалы күлмәкләр,
Нигә бу ялт(ы)равык савытлар?
Шул арба көпчәге астында
Тузанга күмелеп җан бирә,
Кабатлап булмаслык вакытлар.
Утырып сөйләшик әле бер,
Утырып сөйләшик...

РҮЗӘЛ МӨХӘММӘТШИН

МИН ДӘ ҮЛӘРМЕН ӘЛЕ...

(ХИКӘЯ)

< Дәвамы. Башы 26 август санында

Озакламый Шөңгә төшеп җиттек. Машинаны куеп, мәйданга юл тоттык. Ярты Толлы биредә икән! Әйтәм аны үзебездә «скушны» иде шул. Йә берсе исәнләшеп узып китә, йә икенчесенә үзебез төртеләбез. Сыра алдык, кипкән бәрәңге. Рустик сок белән чикләнде.

Бер-ике стаканны корыткач, башыма миңгерәү уй килде: ә нигә төштек соң әле без монда?

– Ничек әнде, монда күңеллерәк ич, – диде Федя, минем, чыннан да, миңгерәү соравыма исе китеп. – Батырга бүләкләр дә әйбәтрәк. Кызлар да чибәррәк.

– Ярар, – дип килештем.

Гәрчә, әлбәттә, арабыздан һичкемнең дә көрәшергә яисә әтәч куарга, яисә һич югы капчык тотып чабышырга теләге юк иде. Кызлары да искитәрлек түгел. Күрше күркәсенә караганда мин үз тавыгымны якынрак күрүчеләрдән.

Тавык дигәннән, ул арада югалып торган Салават пәйда булды. Үзе белән шашлык һәм ике егет алып килгән. Егетләрнең юанрагы кул сузды:

– Ришат.

– Рүзәл.

– Ришат.

– Раил...

– Ришат.

– Фидәрис. – Федя һәрвакыт чын исемен әйтеп таныша иде.

– Ришат.

– Рустам.

– Фирдүс.

– Рүзәл.

Шундый ук тәртиптә Фирдүс белән көрешеп чыктык. Егетләрнең Толлыга төшү теләгеннән януы ачыкланды. Алар фикеренчә, безнең авылда бүләкләр дә затлырак, кызлар да шәбрәк иде. Машинада артык урын булмавын белгәч кенә өметсез кул селтәп, ары уздылар. Ул арада Салават фотоаппарат чыгарды. Шалтшолт күзләрне чагылдырып алды. Баягы егетләр безне күңдерәп өлгергән иде: шашлыкны ашап, сыраны эчеп бетергәч, кире үзебезгә кайтып киттек.

Авылга төшеп җиттек кенә, сөйгәне Ройканы култык астына кыстырды.

– Бушагач кил, – дидем мин. Бәйрәм, тәгаен, дәвам итәчәк иде. Һәм кызына борылдым. – Җибәрерсең бит?

Аның урынына Ройка елмайды:

– Юк, җитәр.

Алар киттеме, мин киттемме – хәтерләмим.

Ләкин исән-имин килеш соңгы очрашуыбыз булды бу...

Хәзер мин бергә төшкән фотоларга – Ройканың соңгы фотоларына! – карыйм. Әйе, Сабан туенда Ройка моңсу иде...

Бераздан мине сюрреалистик, мозаикадан гыйбарәт төшләр били башлады.

Йә этләр ташлана, имеш, йә бүреләр куа...

Йә баш түбәмнән өер-өер үләксә козгыннары кычкырып уза...

Йә өстемә ярканатлар ябырыла...

Мин аларда Ройканы сизә идем. Ачулы кебек иде ул миңа.

Моны аңлату кыен, әмма ул, күзгә чалынмаса да, бу төшләрдә, һичшиксез, бар иде... Белмим, бүре өрүеме, этнең каш астыннан усал карап тын алуымы, кошлар тавышымы, тирә-юнь мохитме – Ройканыкы, дөресрәге – Ройка үзе иде.

Мин төн уртасында куркып, шабыр тирдә туңып уяна башладым. Урамда – җәй югыйсә. Юрганым сыгып алырлык була иде. Йөрәк котырып тибә – ватык су краны сыман, канны туп-туры ми үзәгенә бәрә иде.

Мин отыры йокларга курка башладым.

Мин отыры төннән курка башладым.

Ялгызлыктан курка башладым.

Мин, игезен харап итеп, үз шәүләсеннән куркып яшәгән Кабилгә әйләндем. Һәрбер гайре табигый тавыш, яфрак селкенүе, адымнар (бигрәк тә төнлә!) котымны очырды...

Әмма, Кабилдән аермалы, гаебемнең нидә булуын аңлый алмадым.

Ройка безнең авылда тумады. Себердән кайтып төпләнде алар.

Беренче сыйныфка бергә кердек. Озак еллар бер партада утырдык. Аннары, тугыздан соң, китте ул. Ташчылык буенча укырга керде. Ләкин төзү-салу эшенә яраксыз булып чыкты: биектә кан басымы уйный икән. Мәктәпкә кире кайтты. Яңадан янәшә утыра башладык. Унберне тәмамлаганчы.

Мин, югары очка юл тотканда, шуларны хәтердән кичердем.

Ройканы моргтан алып кайтканнар иде инде.

Капка төбендә халык мәш килә. Читтән караганда, туй гөрли диярсең. Әмма чыр-чу урынына һәммәсе буыла-буыла, үкси-үкси елый иде.

Туганнарын, якын кешеләрен юатырга ашыгучылар да шактый:

– Сащуствую...

– Нык булыгыз инде.

– Бик кызганыч.

Мондый сүзләр колагыма, нишләптер, бер дә юату булып ишетелмәде. Әллә ничек, язгы туфракка кубып төшкән боз сөңгеләредәй, минем дә йомшарган йөрәгемә төшеп кадалды алар, тирән җәрәхәт ясап яралады.

Бу кешеләргә мин ачу белән карадым. Битлек кигән убырлар ясалма сагышлана төсле тоелды.

Башны иеп, өйгә уздым.

Ройка, ап-ак кәфенлеккә төренеп, зал уртасында ята иде. Йөзендә ачу да, борчу да юк. Кастет эзләре генә шәмәхәләнеп чыккан. Йоклый. Күзгеләрне каплап куйганнар. Ройка үзен үле килеш танып сискәнмәсен өчен махсус шулай иткәннәр иде гүя. Уйларга да куркыныч: үзеңне кәфенлектә күр әле!

Уң кулымны мәет өстенә күтәрдем, аның баш ягыннан аякларына таба өч тапкыр йөртеп кабатладым:

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Аның белән бәхилләшергә теләүчеләр күп иде. Һичкемне тоткарламас өчен урамга чыктым. Анда сыйныфташлар җыелган: Ләйсән, Рафил, Дамирә... Күпме гомер күзгә күренмәгән Зөлфия дә биредә. Мәктәпне тәмамлап ничә ел узганнан соң, ниһаять, Ройка аркасында яңадан очраштык.

Көн кызу иде.

Без, кеше-карадан качып, машина артына – күләгәгә чүгәләдек.

– Ни булган соң?

– Чумган да чыкмаган, диләр...

– Ялгызы коенганмы?

– Бер көтү халык!..

– Аңарчы ярты сәгать буе сөйгәне белән сөйләшкән.

– Мескен.

– Салган баштанмы?

– Канында алкоголь тапмаганнар бугай...

– Киемнәре белән баткан бит ул! Иң аңлаешсызы – шул.

– Ой-йо.

– Водолазларны да берәр сәгать үткәч кенә чакыртканнар.

– Ничек инде?

– Шулай.

– Ройка йөзә белми иде! Аннары, салган очракта да, дурак што ли ул киемнәре белән кереп китәргә?..

– Әрәм иткәннәр инде алайса.

– Бли-и-и-н...

– Уеннан уймак?

– Йә, гайбәт сатмыйк инде. Ройкага барыбер хәзер.

– Алла сакласын!

Берникадәр вакыттан соң без, аңгәмәне тәмамлап, ачык капкага бактык: Ройканы алып чыгалар иде.

Зиратка кергәч тә мәетне чирәмгә куйдылар. Тәһарәтле булганнарны мулла үз янына чакырды. Артына ун-унбиш кеше җыелгач, нидер укып алды. Шуннан соң алардан:

– Рамил малае Раил әйбәт кеше идеме? – дип сорады.

– Әйбәт кеше иде, – дип җавап бирделәр аңа.

Мәҗбүри булмаса да, мин дә, эчемнән генә:

– Әйбәт кеше иде, – дип кабатладым.

Әйбәт кеше идеңме соң син, Ройка?

Хак әйттемме?

Әйе, хак, мөгаен.

Гаепнең вак-төяге исә һәр адәм баласында җитәрлек.

– Әйбәт кеше иде!

Ахыры бар >

ҖАЙЛАП УКЫЙ БАШЛЫЙК

Хак лайфхак!

Сентябрь – балалар өчен стресслы вакыт. Бигрәк тә башлангыч сыйныф укучылары өчен. Алар әле балалыктан чыкмаган. Бу киңәшләр ата-аналар колагына.

ЙОКЫ. Балагызны режимга кертегез. Һәрвакыт бер үк вакытта йокларга ятсын һәм бер үк вакытта торсын.

МОХИТ. Балага уңайлы мохит булдырыгыз. Тыныч булмә, җайлы өстәл һәм урындык, уңайлы шкафлар. Дәрес әзерләгән вакытта телефонны алып куегыз.

ДӘРЕСЛӘР. Балага эшләрне планлаштырырга ярдәм итегез. Өй эшләрен эшләгән саен, исемлектә плюсик куйсын. Зур эшләрне вак өлешләргә бүлеп эшләргә өйрәтегез.

ЯЛ ИТҮ. Дәресләргә, өй эшләренә күмелгән укучы өчен ял да бик мөһим. Көннең билгеле бер вакытын ял итүгә бүлеп бирергә кирәк. Бу вакытка бала үзе хуҗа булсын.

БҮЛӘК. Шатландыру чараларын да онытмаска кирәк. Әйтик, тырышкан өчен каядыр алып бару, бүләк алу, тәмле әйбер белән сыйлау h.б.

КИЕМ. Балагызны матур киендерегез. Киемнәрен, тышкы кыяфәтен мактап, һәрвакыт комплиментлар ясагыз. Болай булганда баланың үз-үзенә хөрмәт хисе арта һәм ул мәктәпкә яратыбрак йөри.

МӨҺИМ. Әйткәнебезчә, сентябрь ул – бала өчен дә, ата-аналар өчен дә авыр вакыт. Сынау чоры. Әгәр дә балагыз сез көткәнчә яхшы укымый икән, аны орышырга ашыкмагыз. Берүк абый-апалары, дуслары белән чагыштырып кимсетмәгез. Бала үз эченә йомылырга мөмкин. Киресенчә, аны мактагыз, үсендерегез, укуга кызыксыну уятырга тырышыгыз. Авыр вакыт булса да, бу – бик матур чор. Балагыз үсеп җитеп, тормышта үз юлын тапкач, бу елларны сагынып искә алырсыз әле, Аллаһ боерса!

Әз-мәз мәзәк

* * *

Начар укыган балалар 9 нчы сыйныфтан соң заводка эләгә. Ә яхшы укыганнар – магистратурадан соң.

* * *

Урамда табылган 100 сум шунысы белән яхшы: эшләп алынган 1000 сумнан аермалы буларак, аның өчен салым түлисе юк.

* * *

Иң шәп күчтәнәч ул – карбыз. Үзе арзан, үзе зур. Әле кайвакыт кызыл да була.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: чәчтарашханә, учак, Яланаяклы, Миранов, Булат, экзотика, түти, акр, Эксмо, чор, сөт, Рафинә, Шәфи, әрҗә, ымлык, Илона, кил, япма, Әхмәт, Илнар, хуп, шок, амидол, КАИ, Сокуры, Дорн, ана, Воркута, күч, Базилио, тастымал, балта, шикәр.

Вертикаль: Әсфәндиярова, Әллүки, па, эт, Насери, төнбоек, АМО, аут, Рик, Урта, роялизм, дуст, как, орчык, хор, Аксу, шалтай, яулык, үт, Филипп, чык, Аң, Нәккаш, баш, әби, әр, Али, җиләк, умарта, шәл, Дамирә, үкчә, Оймякон, апостроф, Арамис, Ризаэтдин.

«Су буенда ... яна»
Барбершоп туганы
«Бу көй була, диде, «...!»
«...лы күл» җыры
...-балтай
1912 елгы татар журналы
Шалкан тартучыларның берсе
Бал корты «тулай торагы»
Югарыга менгән өтер
Винера Ганиева укучысы
«... кыз» фильмы
Ят җир әкәмәте
Баянчы ... Хисмәтов

Аяк киеме өлеше
«Кәтүк ..., ник елыйсың»
Шәхсәнәм ...
Мәскәүдә китап нәшрияты
Тупның мәйданнан чыгуы
Алмадан ясала
Инглиз мәйдан берәмлеге
Ул чаба дип бет чаба
Әби кулында
Вакыт, дәвер
Сыер тауары
Корольгә чиксез хакимлек бирү идеологиясе
Тиргәү, орыш

Аһ! Ух! Хм! Ә?
Пугачеваның элеккеге ире
«... бәйләдем, ... бәйләдем»
Язучы Риза ...
Сайлау тартмасы
Мөселман хатыны башында
Өскә каплаган тукыма
«БИМ радио» ди-джее
... Ерикәй
Җырчылар төркеме
«... син, ... син, үзең ...»
Татарча Окей!
Организм реакциясе
«Эх, ...ле җәйләрнең»
КНИТУ -...

«Такси» фильмы актеры
Чеховның «Чайка» герое
Фото чыгаруда кулланыла
Лаеш районы авылы
Элеккеге йөк машинасы
«... и Морти» фильмы
Корт даруы
... Фәхретдин
... куыгы
Дөньядагы иң салкын авыл
Аның күңеле балада
Күп татарлы Коми шәһәре
Кара диңгез, Ак диңгез, ... диңгез
Өем, чүмәлә
Ул эшләмәсә, аяк эшли
Былтыр кулында
Бию элементы
Легендар боксчы
Җырчы ... Сәетова
Буратинодагы хәйләкәр мәче
Кул-сөрткеч
Рөстәм Сәрвәров студиясе
Үлән өстендә тамчы
Ком да, авыру да
Мушкетёр

Беләсең килсә...

1 Александр Македонскийның әнисе ни исемле булган?
а) Илиада;
б) Олимпиада;
в) Универсиада.

2 Ульян өлкәсенең Димитровград шәһәрен татарлар ничек дип атый?
а) Кәрәкәс;
б) Миасс;
в) Мәләкәс.

3 Бу әсәрне Зөлфәт Хәким язган.
а) «Куркү»;
б) «Намус»;
в) «Карурман».

4 Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне.
а) Гашура көне;
б) Бәрәәт кичәсе;
в) Гарәфә көне.

Җаваплар: 1.б); 2.в); 3.а); 4.в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 327

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+